5. Казансу – Идел елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы якынча 140 км, бассейны мәйданы 2600 км. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә Идел елгасына коя.
6. Мишә – Кама елгасының уң кушылдыгы, Куйбышев сусаклагычының Кама култыгына кушыла. Озынлыгы 204 км, бассейны мәйданы 4180 кв.км.
7. Зөя – Идел елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 375 км, бассейны мәйданы 16700 км.
8. Кара Бизнә – Бизнә елгасының сул кушылдыгы. Татарстан Республикасының Чүпрәле районы территориясе буйлап ага. Озынлыгы – 34,0 км, бассейны мәйданы - 242,1 км.

Төбәкнең күпчелек күлләре морфометрик сыйфатлары буенча кечкенә күлләр категориясенә керә. Чагыштырмача зур 30 га якын күл бар (мәйданы 20 – 100 га, шуннан артыграк мәйданлылары да бар). Аеруча зур күлләр: Казан шәһәрендә Урта (112 га), Түбән (56,0 га) һәм Югары Кабан (25,0 га), Казан шәһәре чикләрендә Аккош күле системасы, Лаеш районында Кавал (88,2 га) һәм Тарлаш (60,1), Зеленодольск районында Раифа (32,3 га) һәм Ильинский (27,5 га), «Түбән Кама» милли паркында Подборное (33,0 га) күлләре. Күпчелек күлләр сай сулыкларга карый (1 - 3 м). Карстлы күлләр

арасында, шул исәптән бик кечкенәләре арасында, тирәннәре дә очрый – 20 метрга кадәр һәм тирәнрәк.

Төбәкнең гидрология режимында сусаклагычларның әһәмияте шактый зур:

1. Карабаш сусаклагычы. Карабаш п. янында урнашкан. Карабаш поселогыннан алып Бигеш авылына кадәр аралыкта нефть чыгару һәм сәнәгать предприятиеләре өчен су чыганагы булып тора. Сусаклагычтагы суның тулы күләме – 52,4 млн.куб.м.

2. Түбән Кама сусаклагычы. Вакытлыча билгесе 62,0 м булганда тулы күләме 2,9 куб.км, су өслегенең мәйданы 1,084 мең кв.км. тәшкил итә.

3. Зәй шәһәре янындагы Зәй сусаклагычы. Сусаклагычтагы суның тулы күләме – 0,063 куб.км, су өслегенең мәйданы – 20,45 кв.км.

4. Куйбышев сусаклагычы. Тулы күләме 57,3 куб.км. тәшкил итә. Акваториясе берничә чиктәш төбәк территориясендә, су өслеге мәйданының 50,7 проценты (якынча 3,12 мең кв.км)Татарстан Республикасында урнашкан. Яр сызыгының гомуми озынлыгы – 2604 км, шуның 1392 километры (53,5 %) Татарстан Республикасында урнашкан.

Шунысын әйтеп китәргә кирәк, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары кебек зур сулыкларны хайваннарның яшәү тирәлеге буларак шартлы рәвештә генә карап булмый. Гаять киң булулары сәбәпле, аларда кош-корт, җәнлек-җанварларның күпчелек төрләре оя кора алмый. Текә ярлар, суның еш күтәрелүе һәм төшүе белән бергә, су янында көн итүче төрләрнең үрчүенә киртә була.

## 2.6. Үсемлек капламының сыйфатламасы

Республикада үсемлек капламы нигездә флорогенетика комплексларының бореаль, немораль һәм понтика төрләреннән тора. Флорада шулай ук көнчыгыш (Урал һәм Себер) һәм көньяк-көнчыгыш (Көнчыгыш Европа-Казахстан) элементлары катнашуы сизелә.

Төбәкнең ылыслы мәңге яшел урманнары гадәти чыршыдан (Picea abies), Ак Себер чыршысыннан (Abies sibirica) һәм гадәти нараттан (pínus sylvéstris) тора. Вак яфраклы агач төрләре өстенлек алган катнаш урманнар хәзерге вакытта аеруча таралган. Мондый урманнарда усак (Populus tremula),каен (Betula pendula), вак яфраклы юкә (Tília cordáta) аеруча еш очрый. Тиешенчә Киң яфраклы агач төрләре дә булган катнаш урманнар (киң яфраклы төрләр 30 проценттан кимрәк) һәм киң яфраклы урманнар (киң яфраклы төрләр 30 проценттан артык) азрак мәйданны били. Киң яфраклы төрләр арасында иң күп таралган агач – имән (Quércus róbur). Вак яфраклы агач төрләреннән торган урманнар зур булмаган мәйданда урнаша. Гадәттә зур булмаган күпчелек урман массивларында яшь агачлар өстенлек итә.

Тайга зонасының көньяк чиге булып торган ылыслы урман массивлары территориаль яктан Идел аръягында урнашкан. Аларны составына еш кына төрле санда вак яфраклы һәм киң яфраклы агач төрләре кергән чыршы-ак чыршы һәм нарат урманнары тәшкил итә. Төбәк территориясенең

көньягындарак яфраклы урманнар бар, аларда имән урманнары мөһим урын алып тора. Алар Татарстан Республикасының бөтен районнарында да очрыйлар, көнчыгыш юнәлештә кими баралар. Идел алдында күбесенчә яфраклы, имән үсә торган аз санлы урманнар бар. Төньяк-көнбатыш өлештә катнаш урманнар массивлары урнашкан. Идел-Нократ-Кама субүләрләрендә күпсанлы яфраклы агачлар катнашкан чыршы-ак чыршы төре таралган. Татарстан Республикасының көньяк өлеше урман-дала зонасына керә. Хәзерге вакытта төбәктә дала зонасына карый торган җир кишәрлекләре Кама аръягының көньяк-көнчыгыш субүләрләрендә, шулай ук субүләрләрнең күпчелектә көньякка, көньяк-көнчыгышка, көньяк-көнбатышка караган текә сөзәклекләрендә генә очрый. Бу кишәрлекләр Пермь чорының аларның җир өслегенә якын урнашуы җир сөрүне кыенлаштыра торган (туфрак катлавының калынлыгы 15-20 сантиметрдан артмый) төп токымнарыннан (мергель, мергельле таш һәм балчык) оешкан.

Татарстанның хәзерге заман үсемлекләр капламында шактый зур урынны агрофитоценозлар алып тора. Аларның 91 проценты сөрүлек җирләренә туры килә. Калган мәйданны печәнлекләр һәм көтүлекләр алып тора. Чәчүлек мәйданнарының нигезен бөртекле культуралар тәшкил итә, шулардан бодай (Triticum), арыш (Secále cereále) һәм арпа (Hordeum vulgare) аеруча зур әһәмияткә ия. Азрак дәрәҗәдә кырларга солы (Avéna satíva), карабодай (Fagópyrum) һәм борчак (Pisum sativum) чәчелә. Техник культуралар арасында силос ясау өчен тотыла торган кукуруз (Zéa máys), бәрәңге (Solánum tuberósum) һәм шикәр чөгендере (Beta vulgaris) аеруча зур әһәмияткә ия. Эшкәртелмәгән территорияләрдә чүп үләне төрләре киң таралган.

Татарстан Республикасында коры үзән һәм кыяклы дала үләннәре үсә торган болыннар киң таралган. Зур булмаган тугайлар кечкенә елгалар өчен хас. Болыннар төпләнгән урманнар урынында хасил булган, аларда печән чабалар һәм терлек көтәләр. Татарстанның көньяк районнарында урыны-урыны белән дала куаклыкларыннан торган әрәмәләр очрый, аларның төп төрләре – куаклы чия (Cerasus fruticosa), дала бадәм агачы (Amygdalus nana), спирея (Spiraea crenata), алар шулай ук төпләнгән урман урынында үскән. Көньяк экспозицияләрнең текә сөзәклекләрендә оя-оя дала үләннәре сакланган, шулардан ташлы дала дип аталганнары составына бик борынгы төрләр керә: ике башаклы ылыслы куак (Ephedra distachya), җәелгән кохия (Kochia prostrata), куаклы курчавка (Atraphaxis frutescens). Тозлы туфраклы яшәү тирәлекләрендә галофит үләннәр зур булмаган мәйданда үсә: диңгез сөтлегәне (Glaux maritima), тозлак солерос (Salicornia perennans) һ.б.

Су һәм су яны үсемлекләренең тереклеге сулыкларга һәм су агышына бәйләнгән. Боларның иң күп таралышы Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларына туры килә. Анда су яны үсемлекләреннән озынча яфраклы камыш (Typha angustifolia) һәм гадәти камыш (Phragmites australis) оя-оя булып үсә. Сусаклагычларның һәм күлләрнең су яны үсемлекләре составында зур комай (Glyceria maxima), саз үләне (Eleocharis palustris) һәм кыякларның күп кенә төрләре (Carex) шулай ук шактый зур рольне уйный,

суүсемнәр составында – куе яшел мөгезъяфрак (Ceratophyllum demersum), Канада элодеясы (Elodea canadensis), сары төнбоек (Nuphar lutea) һәм су кәбестәсе төрләре (Potamogeton).

## 2.7. Хайваннар дөньясы

Төбәктәге хайваннар дөньясының байлыгы һәм күптөрлелеге республиканың ике ландшафт зонасы (урман һәм дала) чигендә урнашуына бәйләнгән. Хәзерге вакытта республикада имезүчеләрнең 71 төре, кошларның 290 төре, сөйрәлүчеләрнең 7 төре (Татарстан Республикасы фаунасыннан сазлык ташбакасы юкка чыккан), җир-су хайваннарының 11 төре, балыкларның 43 төре һәм умырткасыз хайваннарның меңәрләгән төре, шуларның биш меңнән артыгы – буынтыкаяклылар, санала («Татарстан Республикасының табигать ресурслары торышы һәм 2019 елда әйләнә-тирә мохитне саклау турында» дәүләт доклады).

Умырткасызлар.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендәге умырткасызларның билгеле бер системага салынган төркемнәрендәге төр күптөрлелеге буенча өзек-төзек мәгълүматлар гына бар. Элпә канатлыларның 304 төре, бызылдавыкларның 303 төре, стафилиннарның 250 дән артык төре, шыртлавык коңгызларның 35 тән алып 50 гә кадәр төре билгеле. Умырткасызларның 107 төре Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән.

Сөякле балыклар.

Күп санлы тикшеренүләр йомгаклары буенча 2012 елда Татарстан Республикасы территориясендәге ихтиология фаунасының 58 төре күрсәтелә, табылган барлык төрләр җилпәзәканатлыларга (Actinopterygii), 11 отряд, 17 семьялык һәм 48 төренә керә. Татарстан Республикасының Кызыл китабына (3 нче басма) балыкларның 11 төре кертелгән. Мәрсин балыгы семьялыгыннан (Acipenseridae) 3 төр - рус мәрсин балыгы (Acipenser gueldenstaedtii), чөгә балыгы (Acipenser ruthenus) һәм кырпы балыгы (Huso huso); карплар семьялыгыннан (Cyprinidae) 4 төр - гадәти маймыч (Rhodeus amarus), гади елгыр балык (Alburnoides bipunctatus),Идел каракойрыгы (Chondrostoma variabile), күлләргесе (Phoxinus percnurus); бәрделәр семьялыгыннан (Thymallidae) 1 төр – Европа бәрдесе (Thymallus thymallus); сөләйман балыгы семьялыгыннан (Salmonidae) 2 төр – таймень (Hucho taimen) һәм инеш керкәсе (Salmo trutta morpha fario); Керчәклеләр мөгезле балыклар семьялыгыннан (Cottidae) 1 төр – гадәти таш асты балыгы (Cottus gobio).

Татарстан Республикасының хәзерге ихтиофаунасы 9 фауна комплексыннан тора. Бүтән сулыклардагы кебек, Урта Идел бассейнының ихтиофаунасы нигезен ике фауна комплексы тәшкил итә: 13 бореаль тигезлек төре (чуртан, бәртәс, чабак, карабалык, гадәти кәрәкә, көмеш кәрәкә, гадәти щиповка, Себер щиповкасы, күл ләргесе, йомры чабак, гадәти ташбаш, алабуга, шыртлака) һәм унөч понто-каспий төче сулык төре (кызылканат,

верховка, җилембалык, корбан балыгы, тәлпияк, ак каурыйлы ташбаш, синец, аккүз, быстрянка, опты, түбәнавыз, кушбаш, чехонь). Балыкларның 9 төре амфибореальгә керә (судак, сазан, этләч, сула, җәен, маймыч, кырпы балыгы, чөгә, мәрсин), понто-каспий диңгез – 6 төр (пуголовка, кушбаш, йомры кискә, цуцик, энә, тюлька), тау яны бореаль – 5 төр (елга ләргесе, мыеклы сагалак, бәрде, таймень, таш асты балыгы), Кытай-тигезлек – 3 төр (ак ташмаңгай, чуар ташмаңгай, амур). Татарстан Республикасы ихтиофаунасында һинд-тигезлек (ротан) һәм атлантик диңгез комплексыннан (еланбалык) берешәр төр бар.

Җир-су хайваннары һәм сөйрәлүчеләр.

Татарстан Республикасының җир-су хайваннары һәм сөйрәлүчеләр фаунасында 2 төркем җир-су хайваны һәм 2 төркем сөйрәлүче бар: ташбакалар (Testudines), тәңкәлеләр (Squamata), койрыклылар (Caudata) һәм койрыксызлар (Anura). Беренче сыйныфка 5 семьялык керә: төче су ташбакалары (Emididae) (1 төр), бакыр еланнар (Anguidae) (1 төр), чын кәлтәләр (Lacertidae Cope) (2 төр), тузбашлар(Colubridae) (2 төр), кара еланнар (Viperidae) (2 төр). Икенчесенә саламандрлар семьялыгы (Salamandridae) (2 төр), түгәрәктеллеләр (Discoglossidae) (1 төр), сарымсак килеселәре (Pelobatidae) (1 төр), гөберле бакалар (Bufonidae) (2 төр) һәм бакалар (Ranidae) (5 төр) керә. Сөйрәлүчеләрдән 4 төр (барлык сөйрәлүчеләр төреннән 62,5%) һәм җир-су хайваннарыннан 3 төр (барлык җир-су хайваннарыннан 27,2%) Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән.

Кошлар.

Татарстан Республикасының орнитофаунасында чыпчыксыманнар төркеме (Passeriformes) аеруча нык таралган – 154 төр. Бу отрядта сан ягыннан чебенчеләр, миләш чыпчыклары һәм тау чыпчыклары өстенлек итә. Чыпчыксыман (Charadriiformes), казсыман (Anseres) һәм лачынсыман (Falconiformes) кош төркемнәре шулай ук төр ягыннан шактый бай.

Кошларның күпчелеге – күчмә кошлар. Кошларның якынча 40 төре ау кошлары булып санала. Елга үрдәкләре күп, чүрәкәйләр сан ягыннан шактый кайтыш.

Имезүчеләр.

Имезүчеләр исемлегенә 71 төр хайван кертелгән, әле тагын чүл бүресенең, Европа чәшкесенең, ярканатларның берничә төренең статусын анықларга кирәк Рус җофарын югалган төр дип танырга кирәктер, мөгаен. Ландшафтның төрлелеге (урман, дала, урман-дала, су яны һәм су комплекслары, бик борынгы һәм аз үзгәргән территорияләр) һәм аерым биотопларның чуарлыгы аркасында, Татарстан Республикасы территориясендә имезүчеләр составы катнаш характерда.

Аучылык ресурслары.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларына хайваннарның 78 төре керә, шуларның 30 төре – имезүчеләр һәм 48 төре – кошлар. Татарстан Республикасының аучылык ресурслары

структурасында аучылык хуҗалыгында киң кулланыла торган төрләр өстенлек итә. Республикадагы аучылык ресурсларының төрләргә бүленеше 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица

Татарстан Республикасындагы аучылык ресурсларының төрләргә бүленеше

| Т/с | Аучылык ресурслары төрләренең татарча атамасы | Аучылык ресурслары төрләренең латинча атамасы |
|---|---|---|
| Төрләр | | |
| ИМЕЗҮЧЕЛӘР КЛАССЫ (Mammalia) | | |
| КУШТОЯКЛЫЛАР отряды (Artiodactyla) | | |
| Боланнар семьялыгы (Cervidae) | | |
| 1 | Поши | Alces alces |
| 2 | Себер кыр кәҗәсе | Capreólus pygárgus |
| 3 | Европа кыр кәҗәсе | Capreolus capreolus |
| Дуңгызлар семьялыгы Suidae | | |
| 4 | Кабан дуңгызы | Sus scrofa |
| ЕРТКЫЧЛАР отряды (Carnivora) | | |
| Бүреләр семьялыгы (Canidae) | | |
| 5 | Бүре | Canis lupus |
| 6 | Гади төлке | Vulpes vulpes |
| 7 | Янутсыман эт | Nyctereutes procyonoides |
| 8 | Дала төлкесе | Vulpes corsac |
| Мәчеләр семьялыгы (Felidae) | | |
| 9 | Селәүсен | Felis lynx |
| Сусарлар семьялыгы (Mustelidae) | | |
| 10 | Бурсык | Meles meles |
| 11 | Урман сусары | Martes martes |
| 12 | Дала көзәне | Mustela eversmanni |
| 13 | Урман көзәне | Mustela putorius |

| Т/с | Аучылык ресурслары төрләренең татарча атамасы | Аучылык ресурслары төрләренең латинча атамасы |
|---|---|---|
| 14 | Себер бурсыгы | Gulo gulo |
| 15 | Ләтчә | Mustela nivalis |
| 16 | Америка чәшкесе | Mustela vison |
| 17 | Себер көзәне | Mustela sibirica |
| 18 | Кама | Lutra lutra |
| 19 | Ас | Mustela erminea |
| Аюлылар гаиләсе (Ursidae) | | |
| 20 | Көрән аю | Ursus arctos |
| КИМЕРҮЧЕЛӘР отряды (Rodentia) | | |
| Кондызлар семьялыгы (Castoridae) | | |
| 21 | Елга кондызы | Castor fiber |
| Тиеннәр семьялыгы (Sciuridae) | | |
| 22 | Гади тиен | Sciurus vulgaris |
| 23 | Дала байбагы | Marmota bobak |
| 24 | Зур (җирән) йомран | Citellus major |
| Әрләннәр семьялыгы (Cricetidae) | | |
| 25 | Су күсесе | Ondatra zibethica |
| 26 | Гади әрлән | Cricetus cricetus |
| 27 | Су кыр тычканы | Arvicola terrestris |
| КУЯННАР отряды (Lagomorpha) | | |
| Куяннар семьялыгы (Leporidae) | | |
| 28 | Соры куян | Lepus europaeus |
| 29 | Ак куян | Lepus timidus |
| БӨҖӘКАШАУЧЫЛАР отряды (Insectivora) | | |
| Сукыр тычканнар семьялыгы (Talpidae) | | |
| 30 | Европа сукыр тычканы | Talpa europaea |

| Т/с | Аучылык ресурслары төрләренең татарча атамасы | Аучылык ресурслары төрләренең латинча атамасы |
|---|---|---|
| КОШЛАР КЛАССЫ (Aves) | | |
| ТАВЫКСЫМАННАР отряды (Galliformes) | | |
| Кыргавыллар семьялыгы (Phasianidae) | | |
| 31 | Соры кыр тавыгы | Perdix perdix |
| 32 | Бүдәнә | Coturnix coturnix |
| Көртлекләр семьялыгы (Tetraonidae) | | |
| 33 | Божыр | Tetrastes bonasia |
| 34 | Гадәти урман тавыгы | Tetrao urogallus |
| 35 | Көртлек | Lyrurus tetrix |
| 36 | Ак кыр тавыгы | Lagopus lagopus |
| ТОРНАСЫМАННАР отряды (Gruiformes) | | |
| Көтүче кошлар семьялыгы (Rallidae) | | |
| 37 | Су тавыгы | Fulica atra |
| 38 | Тартар | Crex crex |
| 39 | Гади кугыч | Porzana porzana |
| КАЗСЫМАННАР отряды (Anseriformes) | | |
| Үрдәк кошлар семьялыгы (Anatidae) | | |
| 40 | Ак маңгайлы каз | Anser albifrons |
| 41 | Ындыр казы | Anser fabalis |
| 42 | Соры каз | Anser anser |
| 43 | Чуар үрдәк | Tadorna tadorna |
| 44 | Кыр үрдәге | Anas platyrhynchos |
| 45 | Сыбызгы-чүрәкәй | Anas crecca |
| 46 | Черелдек-чүрәкәй | Anas querquedula |
| 47 | Соры үрдәк | Anas strepera |
| 48 | Безкойрык | Anas acuta |

| Т/с | Аучылык ресурслары төрләренең татарча атамасы | Аучылык ресурслары төрләренең латинча атамасы |
|---|---|---|
| 49 | Киң борынлы үрдәк | Anas clypeata |
| 50 | Сыбызгы-үрдәк | Anas penelope |
| 51 | Ала чумгалак | Bucephala clangula |
| 52 | Бүрекле кара үрдәк | Aythya fuligula |
| 53 | Кызыл үрдәк | Tadorna ferruginea |
| 54 | Кызыл башлы чумгалак | Aythya ferina |
| 55 | Четерек | Netta rufina |
| 56 | Диңгез кара үрдәге | Aythya marila |
| 57 | Ак күз кара үрдәге | Aythya nyroca |
| 58 | Ак яңаклы казарка | Branta leucopsis |
| 59 | Чумгалак үрдәк | Mergus merganser |
| 60 | Тундра-диңгез чумгалагы | Clangula hyemalis |
| 61 | Ак чумгалак | Mergellus albellus |
| ЧЫПЧЫКСЫМАННАР отряды (Charadriiformes) | | |
| Чуллыклар семьялыгы (Scolopacidae) | | |
| 62 | Чуллык | Gallinago gallinago |
| 63 | Урман үрдәге | Gallinago media |
| 64 | Теләттәвеч | Scolopax rusticola |
| 65 | Мородунка | Xenus cinereus |
| 66 | Кечкенә веретенник | Limosa lapponica |
| 67 | Уртача кроншнеп | Numenius phaeopus |
| 68 | Нәни Кроншнеп | Numenius minutus |
| 69 | Гаршнеп | Lymnocryptes minimus |
| 70 | Корыхтан | Philomachus pugnax |
| 71 | Гадәти таш асты балыгы | Arenaria interpres |
| Арыш чыпчыклары гаиләсе (Charadriidae) | | |

| Т/с | Аучылык ресурслары төрләренең татарча атамасы | Аучылык ресурслары төрләренең латинча атамасы |
|---|---|---|
| 72 | Бибек | Vanellus vanellus |
| 73 | Соры арыш чыпчыгы | Charadrius morinellus |
| 74 | Тулес | Pluvialis squatarola |
| КҮГӘРЧЕНСЫМАННАР отряды (Columbiformes) | | |
| Күгәрченнәр гаиләсе (Columbidae) | | |
| 75 | Күгелҗем күгәрчен | Columba livia |
| 76 | Әберчен | Columba palumbus |
| 77 | Боҗралы урман күгәрчене | Streptopelia decaocto |
| ЧЫПЧЫКСЫМАННАР Отряды (Passeriformes) | | |
| Каргалар гаиләсе (Corvidae) | | |
| 78 | Соры карга | Corvus cornix |

Саклана торган төрләр.

«Ау турында» гы законның 11 маддәсенең 4 пункты нигезендә, Россия Федерациясенең Кызыл китабына һәм Россия Федерациясе субъектларының Кызыл китапларына кертелгән имезүчеләрне һәм кошларны тоту тыела.

Татарстан Республикасы территориясендә имезүчеләрнең саклана торган төрләренә түбәндәгеләр кертелә:

Колаклы керпе (Erinaceus auritus, Gmelin, 1770), гади кутора (Neomys fodiens, Pennant, 1771), кечкенә шолган (Sorex minutissimus, Zimmermann, 1780), Наттерер төн күбәләге (Myotis nattereri, Kuhl, 1817), мыеклы төн күбәләге (Myotis mystacinus, Kuhl, 1819), Брандт төн күбәләге (Myotis brandti, Eversmann, 1845), Бөя төн күбәләге (Myotis dasycneme, Boie, 1852), су төн күбәләге (Myotis daubentoni, Kuhl, 1817), озын колаклы көрән ярканат (Plecotus auritus, Linnaeus, 1758), гигант кичке ярканат (Nyctalus lasiopterus, Schreber, 1780), кәрлә ярканат (Pipistrellus pipistrellus, Schreber, 1774), зур урман ярканаты (Pipistrellus nathusii Keyserling, Blasius, 1839), төньяк ярканаты (Eptesicus nilssoni Keyserling, Blasius, 1839), ике төсле ярканат (Vespertilio murinus, Linnaeus, 1758), ак куян (Lepus timidus, Linnaeus, 1758), гади очкалак (Pteromys volans, Linnaeus, 1758), Азия борындыгы (Tamias sibiricus, Laxmann, 1769), тимгелле йомран (Citellus suslicus, Guldenstaedt, 1770), урман төнгелеге (Dryomys nitedula, Pallas, 1778), бакча төнгелеге (Eliomys quercinus, Linnaeus, 1766), полчок (Myoxus glis, Linnaeus, 1766), чикләвек төнгелеге (Muscardinus avellanaruis, Linnaeus, 1758), дала тычканчыгы (Sicista subtilis, Pallas, 1773), урман тычканчыгы (Sicista betulina, Pallas, 1779), Эверсман әрләне (Allocricetulus eversmanni, Brandt, 1859), соры

эрлән (Cricetulus migratorius, Pallas, 1770), дала соры тычканы (Lagurus lagurus, Pallas, 1773), зур кушаяк (Allactaga major, Kerr, 1792), кызыл кыр тычканы (Myodes rutilus, Pallas, 1779), көрән аю (Ursus arctos, Linnaeus, 1758), ташлык сусары (Martes foina, Erxleben, 1777), Европа чәшкесе (Mustela lutreola, Linnaeus, 1761), кама (Lutra lutra, Linnaeus, 1758).

Татарстан Республикасы территориясендә саклана торган кошларга түбәндәгеләр керә:

Кара бүксәле күл кошы (Gavia arctica, Linnaeus, 1758), кызыл муенлы поганка (Podiceps auritus, Linnaeus, 1758), соры яңаклы поганка (Podiceps grisegena, Boddaert,1783), зур күлбога (Botaurus stellaris, Linnaeus, 1758), кечкенә күлбога (Ixobrychus minutus, Linnaeus, 1766), зур ак челән (Egretta alba, Linnaeus, 1758), кара ләкләк (Ciconia nigra, Linnaeus, 1758), кызыл бүксәле диңгез казы (Rufibrenta ruficollis, Pallas, 1769), соры каз (Anser anser, Linnaeus, 1758), чыелдык (Anser erythropus, Linnaeus, 1758), ысылдавык аккош (Cygnus olor, Gmelin, 1789), кыйгак аккош (Cygnus cygnus, Linnaeus, 1758), кызыл үрдәк (Tadorna ferruginea, Pallas, 1764), балыкчы карчыга (Pandion haliaetus, Linnaeus, 1758), гади шөпшәашар (Pernis apivorus, Linnaeus, 1758), кыр карчыгасы (Circus cyaneus, Linnaeus, 1766), дала карчыгасы (Circus macrourus, S. G. Gmelin, 1771), болын карчыгасы (Circus pigargus, Linnaeus, 1758), елан ашаучы кош (Circaetus gallicus, Gmelin, 1788), кәрлә бөркет (Hieraaetus pennatus, Gmelin, 1788), зур бөркетсыман кош (Aquila clanga, Pallas, 1811), кабер кошы (Aquila heliaca, Savigny, 1809), бөркет (Aquila chrysaetos, Linnaeus, 1758), ак койрыклы диңгез бөркете (Haliaetus albicilla, Linnaeus, 1758), шоңкар (Falco rusticolus, Linnaeus, 1758), балобан (Falco cherrug, Gray, 1834), сапсан (Falco peregrinus, Tunstall, 1771), дербник (Falco columbarius, Linnaeus, 1758), ягылбай (Falco vespertinus, Linnaeus, 1766), гади торымтай (Falco tinnunculus, Linnaeus, 1758), дала торымтае (Falco naumanni, Fleischer, 1818), соры торна (Grus grus, Linnaeus, 1758), пастушок (Rallus aquaticus, Linnaeus, 1758), камыш чыпчыгы (Gallinula chloropus, Linnaeus, 1758), шөлди-саескан (Haematopus ostralegus, Linnaeus, 1758), зур улит (Tringa nebularia, Gunnerus, 1767), травник (Tringa tetanus, Linnaeus, 1758), поручейник (Tringa stagnatilis, Bechstein, 1803), зур кроншнеп (Numenius arquata, Linnaeus, 1758), зур шөлди (Limosa limosa, Linnaeus, 1758), кара башлы шаркылдык (Larus ichthyaettus, Pallas, 1773), кече акчарлак (Lams minutus, Pallas, 1776), кече диңгез акчарлагы (Sterna albifrons, Pallas, 1764), клинтух (Columba oenas, Linnaeus, 1758), гади урман күгәрчене (Streptopelia turtur, Linnaeus, 1758), ак ябалак (Nyctea scandiaca, Linnaeus, 1758), байгыш (Bubo bubo, Linnaeus, 1758), колаклы ябалак (Asio otus, Linnaeus, 1758), саз ябалагы (Asio flammeus, Pontoppidan, 1763), кечкенә ябалак (Otus scops, Linnaeus, 1758), чырайсыз йонлач аяклы ябалак (Aegolius funereus, Linnaeus, 1758), чырайсыз йорт ябалагы (Athene noctua, Scopoli, 1769), чырайсыз чыпчык ябалагы (Glaucidium passerinum, Linnaeus, 1758), карчыга ябалагы (Surnia ulula, Linnaeus, 1758), соры ябалак (Strix aluco, Linnaeus, 1758), озын койрыклы соры ябалак (Strix uralensis, Pallas, 1771), гади төн күгәрчене (Caprimulgus europaeus, Linnaeus, 1758), күк карга (Coracias garrulus, Linnaeus,

1758), гади кыштуар (Alcedo atthis, Linnaeus, 1758), һөдһөд (Upupa epops, Linnaeus, 1758), яшел тукран (Picus viridis, Linnaeus, 1758), чал тукран (Picus canus, Gmelin, 1788), өч бармаклы тукран (Picoides tridactylus, Linnaeus, 1758), соры соркопут (Lanius excubitor, Linnaeus, 1758), эрбет чыпчыгы (Nucifraga caiyocatactes, Linnaeus, 1758), зәңгәр чыпчык (Parus cyanus, Pallas, 1770).

## 3. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый сыйфатламасы

### 3.1. Татарстан Республикасы территорияләре административ бүленеше карта-схемасы

Беркетелгән һәм һәркем файдалана ала торган аучылык биләмәләренең, шулай ук аучылык ресурслары яши торган, ләкин аучылык биләмәләренә кертелмәгән башка территорияләрнең Татарстан Республикасы буенча урнашуы төбәкнең административ бүленеше карта-схемасында күрсәтелгән (1 нче кушымта). Карта-схема аучылык биләмәләре, аерым саклана торган табигать территорияләре турында мәгълүматны исәпкә алып эшләнде һәм аңа зарури топография катламнары – рельеф, үсемлекләр һ.б. – керә.

### 3.2. Татарстан Республикасында аучылар саны турында мәгълүмат

Татарстан Республикасында аучылык прессы, кагыйдә буларак, җирле аучылар хисабыннан формалаша, бу исә республикада чит ил һәм төбәкара аучылык туристлыгының үсмәвенә бәйле.

Аучылык билетларының ике варианты күздә тотыла: әгъзалык аучылык билеты һәм бердәй федераль үрнәктәге аучылык билеты. Шул ук вакытта ауга рөхсәт бирүче таныклык булып бары бердәй федераль үрнәктәге аучылык билеты гына тора. Шулай итеп, аучының хокукый статусы дәүләт аучылык билеты булуга бәйле («Ау турында» законның 20 статьясы).

Бердәй федераль үрнәктәге аучылык билетлары республикада вәкаләтле дәүләт органы – Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе тарафыннан бирелә. Әгъзалык аучылык билетлары гражданнарга аучыларның тиешле иҗтимагый оешмалары тарафыннан бирелә. Бердәй аучылык билеты бирелгәндә, әгъзалык аучылык билеты калдырыла һәм иҗтимагый оешмада торучыларга төрле, шул исәптән икътисадый ташламалар бирә ала торган әлеге оешмада гражданның әгъза булуын раслый торган документ булып тора.

Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетлары 2011 елның 1 июленнән бирелә. 2020 елның 1 декабренә Татарстан Республикасында мондый төрдәге 59 152 билет бирелгән. «Ау турындагы» Законның 20 статьясы нигезендә хокукый затның яки шәхси эшмәкәрнең хезмәт шартнамәсе яисә граждан-хокукый шартнамә нигезендә ау яки аучылык ресурсларын саклау белән бәйле вазыйфаларын үти торган хезмәткәре аучыга тиңләнә. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә аучылык өлкәсендә эшли торган

66 юридик зат теркәлгән. Моннан тыш, аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек алып баручы 4 шәхси эшкуар теркәлгән.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм иҗтимагый аучылык оешмаларына керүче гражданнар саны якынча 18 000 кеше тәшкил итә. Шулай итеп, республиканың 50 % аучысы иҗтимагый аучылык оешмаларында әгъза булып торуны хуп күрә.

Татарстан Республикасында «Росохотрыболовсоюз ассоциациясе» Аучылар һәм балыкчылар бөтенроссия иҗтимагый берләшмәсе ассоциациясенә керүче бер иҗтимагый оешма – «Татарстан Республикасының аучылар һәм балыкчылар җәмгыяте» («Татохотрыболовобщество» төбәк иҗтимагый оешмасы) төбәк иҗтимагый оешмасы теркәлгән. Хәзерге көндә «Татохотрыболовобщество» төбәк иҗтимагый оешмасы аучылык хуҗалыкларында бәя куюга караш болайрак: иң актив аучыларга иҗтимагый аучылык оешмасы әгъзасы булу икътисадый яктан табышлырак, чөнки иҗтимагый оешмада әгъза булмаган аучылар ау хезмәтләре өчен уртача ике тапкырга артыграк түли. Аучылык җәмгыятьләре әгъзалары (аучыларның 50 проценты) – ау коралы ияләре генә түгел, бәлки төбәк территориясендә ау белән актив шөгыльләнүчеләр булып тора дип, билгеле бер дәрәҗәдә ышанып әйтергә мөмкин. Бу раслау, әгъзалык аучылык билеты ияләреннән аермалы буларак, дәүләт аучылык билеты ияләренең кертемнәр һәм башка түләүләр рәвешендә еллык һәм башка вакытлы чыгымнары булмавына нигезләнә. Ягъни, аучы статусы булган һәм ау белән шөгыльләнергә теләгән гражданнарга икътисадый яктан оешмада тору отышлырак. Ә аучы статусына (һәм дәүләт аучылык билетына) ия булып та, ау белән шөгыльләнмәүче гражданнарга иҗтимагый оешмада әгъзалык өчен акча чыгармау отышлырак. Шулай итеп, төбәк территориясендә аучылык прессы турыдан-туры гомуми аучылар санының 50 процентыннан формалаша.

Шунысын да әйтергә кирәк, Татарстан Республикасының аучылык биләмәләренә транспортта кереп булганга күрә, аучыларга, яшәү урыны республиканың бер районында теркәлгән булса да, башка районнарда (яшәгән районы белән чиктәш булмаска да мөмкин) ау белән шөгыльләнү мөмкинлеге бирә һәм чынлыкта бу шулай килеп чыга да. Шуңа күрә теге яки бу аучылык биләмәләренә аучылык йөкләнешен бәяләгәндә, аучыларның яшәү урыннары районнар буенча бүленешен бәяләү әһәмияткә ия булмый.

## 3.3. Татарстан Республикасында аучылык ресурсларына һәм аларның яшәү тирәлегенә антропоген йогынтының характеры һәм көче

1. Татарстан Республикасының территория ягыннан һәм социаль-икътисадый үсешенең хәзерге торышы.

Татарстан Республикасында 956 муниципаль берәмлек, шул исәптән 43 муниципаль район бар. Төбәк территориясендә федераль магистраль тимер юллар һәм автомобиль юллары, магистраль газүткәргеч һәм нефтьүткәргеч системалары, Россиянең Европа өлешенең Каспий, Урта

диңгез һәм Балтыйк бассейннарына чыга торган бердәм су системасы, көнбатыштан көнчыгышка һәм төньяктан көньякка, Россия Федерациясе төбәкләренә һәм Татарстан Республикасы эчендә йөк һәм пассажирлар ташуны тәэмин итә торган һава трассалары үтә. Әлеге магистраль транспорт элемтәләре Казан транспорт узелында кисешә. Татарстан Республикасының көчле агросәнәгать комплексы бар. Татарстан Республикасы үсемлекчелек продукциясенең төп төрләрен җитештерүдә (бөртеклеләрнең тулай уңышы, бәрәңгенең тулай уңышы, рапсның тулай уңышы) һәм терлекчелек (сөт җитештерү, терлек һәм кош үрчетү) буенча алдынгылар рәтендә тора.

2. Татарстан Республикасында аучылык ресурсларына һәм аларның яшәү тирәлегенә антропоген йогынты характеры һәм көче.

Аучылык ресурсларына һәм аларның яшәү тирәлегенә, тикшерелә торган объектларга йогынты ясауның төп факторы буларак, аучылыкны санамаганда, антропоген йогынты аларга уңай да, тискәре дә йогынты ясаучы күпчелек факторлардан тора.

2.1. Урман хуҗалыгы тәэсире.

Татарстан Республикасының урман хуҗалыгы Татарстан Республикасының Урман планы, урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентлары нигезендә, урманнан файдалануның тотрыклы принципларына таянып, әйләнә-тирә табигатькә зыян китерми торган ысуллар белән алып барыла. Моннан тыш, республикада «Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасы гамәлдә.

Урман үсемлекләре һәм урманда яшәүче аучылык ресурслары урман биогеоценозларының состав өлешләре булып тора. Ау җәнлекләре һәм кошлары составындагы төрләр һәм аларның саны турыдан-туры урман үсемлекләренең нинди характерда булуына бәйле, ә алар исә күпчелек очракта үсентеләр төрләренең составы һәм аларны яңарту стадиясе белән билгеләнә.

Татарстан Республикасының аучылык хуҗалыгына карата шунысын билгеләп китәргә кирәк: территориядә урманнар аз булганга, урманда аучылык биләмәләре составының сыйфатындагы нинди дә булса үзгәрешләр төбәктә тулаем аучылык биләмәләренең сыйфатында тамырдан үзгәрешләр китереп чыгара алмый. Әмма аучылык фаунасының аерым төрләре өчен урман биләмәләре, яшәү тирәлегенең мөһим элементы буларак, зур әһәмияткә ия була. Болар аеруча авыр кышкы чорда урманда тупланып яшәүче кыргый тояклы хайваннарга, ә шулай ук урман киекләренә кагыла.

Урманнан файдалану традицион рәвештә карт һәм өлгергән агач урманнарында тоташтан һәм сайлап агач кисү вакытында башкарыла торган орган үзагач хәзерләүне күздә тота. Ләкин өлгергән һәм карт агачлардан торган урманнар республиканың урманнар үсә торган 23 процент мәйданын алып торганлыктан, һәм ел саен 1 гектар урманнан 0,76 куб.м ликвид үзагач кына киселгәнлектән, үзагач хәзерләү күләме хәзерге вакытта аучылык ресурсларына зур йогынты ясамый.

Республика урманнарында агач кисүләрнең төп төре – үсентеләрне тәрбияләүгә юнәлтелгәннәре. Ау хайваннарының яшәү тирәлегенә мондый

кисүләр ике төрле йогынты ясый. Бер яктан, бу урманда яктылык артуга ярдәм итә һәм, кагыйдә буларак, хайваннар туклана торган ботак, үсемлек, җиләк-җимешләрнең массасы артуга китерә. Шул ук вакытта, мәйдан ачылганлыктан, биләмәләрне саклау шартлары яхшыра. Бу фактор кайбер төрләр өчен, әйтик, суер, көртлек, боҗыр өчен үтә мөһим, ә поши өчен ул иң беренчел әһәмияткә ия була. Моннан тыш, сирәкләнгән урманнарда киек кошлар өчен оялау һәм бала чыгару өчен шартлар яхшыра. Икенче яктан, үсентеләрне тәрбияләүгә юнәлтелгән агач кисү ау хайваннарына һәм кошларына ризык булган төп төр булмаган агачларны һәм куакларны кисү белән бәйле. Әйтик, ылыслы урманнарда усак һәм яфраклы башка агач төрләрен кисү күпчелек хайваннар өчен азык сыйфаты начараюга китерә.

Урман хуҗалыкларының регламентында үзагачтан тыш, башка урман ресурсларын (каен тузы, кабык, ботаклы терлек азыгы һ.б.) һәм урмандагы азык ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю кебек эшләр өчен урманнардан файдалануга мәйданнар билгеләнгән, әмма аларның чимал базасы зур булмаганга, алар киң таралыш алмыйлар. Шунлыктан, урманнан файдалануның күрсәтелгән төрләре урмандагы аучылык биләмәләренең сыйфатына берничек тә йогынты ясамый.

Аучылык ресурсларына һәм аларның яшәү тирәлегенә урман янгыннары тискәре йогынты ясый, шунлыктан урманны янгыннан саклау – аучылык ресурсларының куркынычсызлыгын тәэмин итүдә иң мөһим нәрсәләрнең берсе.

Махсус рәвештә урман утырту аучылык ресурсларына һәм аларның яшәү тирәлегенә уңай йогынты ясый. Махсус утыртылган урманнар челтәре билгеле бер максатларда җирләрне сөрү белән бәйле рәвештә барлыкка килде. Урман полосалары нигездә иген кырларын, бакчаларны һәм сулыкларны шактый ешайган коры җилләрдән саклау өчен утыртыла. Татарстан Республикасы территориясендә көнчыгыш һәм көнбатыш җилләр өстенлек иткәнгә, мондагы күпчелек урман полосалары меридиан юнәлешендә, азрак өлеше аркылы киңлек юнәлешендә утыртылган. Махсус утыртылган урманнар хайваннарның күпчелек төре өчен ремизлар ролен уйный, алар бу урманнарны саклану һәм оя ясау стацияләре буларак кулланалар. Махсус утыртылган урманнарда җимеш агачларының һәм куаклыкларның күп булуы хайваннарның азыгын арттыра. Соңгы вакытта Татарстан Республикасында урманнарны яңарту эше киң колачлы алып барыла, аның төп юнәлешләре – урманнарны торгызу һәм киңәйтү. Урман торгызу фонды күпчелектә кисентеләр һәм аланлыклардан тора. Абсолют берәмлекләрдә кисентеләр – 4,7 мең гектар, ташландык урыннар һәм аланлыклар 4,0 мең га, корыган агачлар 0,1 мең га тәшкил итә. Урманны торгызу өчен 8,8 мең га урман җирләре кирәк булачак. Бу эштә табигый, ясалма һәм катнаш ысуллар файдаланыла.

2.2. Авыл хуҗалыгы йогынтысы.

Соңгы йөз елда төбәктә халык саны арту шәһәрләр һәм бистәләр, сәнәгать предприятиеләре, юллар, газ- һәм нефтьүткәргечләр салынган территорияләрнең шактый артуына китерде, Татарстан Республикасының зур

җир мәйданнары сусаклагычлар астында калды. Урманнарны бетерү һәм җирләрне сөрү табигый процессларның бөтен системасындагы динамик тигезлекне какшатты. Һаваның һәм туфракның дымлылыгы кимеде, температура үзгәрешләре ешайды. Урмансыз калган бушлыкларда кар катламының калынлыгы кими һәм туфракка туң тирәнрәк төшә, бу ау хайваннарының күпчелек төрләре популяциясенә начар тәэсир ясый. Туфрак тузанлыга әйләнә, аның структурасы бозыла, бу аның су сеңдерүчәнлеген байтак начарайта. Болар җир асты һәм җир өсте су агымнарының яңача бүленешенә һәм соңгысының роле артуга китерә. Җир өсте агымнарының артуы нәтиҗәсендә сөрелгән җирләрдә табигый урман һәм урман-дала ландшафтлары шартларында бөтенләй чагылыш тапмый торган диярлек эрозия процесслары – туфракның һәм чокырларның эрозиясе – кискен көчәеп китә. Әйтик, Казанка елгасы бассейнында чокыр-сыза челтәре 100 ел эчендә 0,22 дән 0,36 кадәр; Мишә елгасы бассейнында 0,36 дан 0,92 км/кв. км кадәр артты. Шул вакыт эчендә эрозия процессы табигый модификациядән бермә-бер тизрәк баручы табигый-антропоген модификациягә үзгәрде.

Республика территориясенең төп өлеше агроценозлардан торганга, аларны эшкәртү барышында басуларда яши торган җәнлекләрнең күпчелеге качып бетә. Махсус тикшеренүләр мәгълүматларына караганда, механикалаштырылган авыл хуҗалыгы эшләре вакытында, җәйге чорда агроценозларда яши торган төрле ау җәнлекләре балаларының якынча 70 проценты кырыла. Шул ук вакытта, үлән чапканда, ашлык һәм бүтән авыл хуҗалыгы культураларын җыйганда боларның кырылуына механикалаштырылу гына да түгел, бәлки житештерү процессы – эш ысуллары һәм алымнары сәбәпче була.

Аучылык ресурслары популяциясенең торышын авыл хуҗалыгында химия препаратлары куллану, аеруча аларны куллану таләпләрен бозу тискәре чагылыш таба. Әйләнә-тирә мохитне йогынтысы бетми торган матдәләр белән пычрату хайваннар организмының әкренләп агулануына, аларның авырый башлавына һәм үлеменә сәбәп була. Күпчелек очракта җир өсте хайваннары һәм кошлар тычкансыман кимерүчеләргә каршы көрәшү өчен таратылган агуланган бөртекле алдавычлар ашаудан һәлак була.

Хәзерге вакытта сөрүлек җирләрдә урманнар аз булган (4,7–7 % оптималь дәрәҗә булып саналганда, 2,5 % тәшкил итә) авыл хуҗалыгы җирләренең күп өлеше сукаланган булуы, территориядә урманнарның азлыгы эрозия һәм дефляция процессларының артуына китерә. Туфракны фотога төшерү мәгълүматларына караганда, эрозияле һәм дефляцияле җирләр арта бара. Бу процесслар Әгерҗе, Әтнә, Балтач, Биектау, Лаеш, Мамадыш, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба һәм Теләче районнарында аеруча интенсив бара. Эрозияле җирләр мәйданы (сөрүлек җирләрнең гомуми мәйданыннан) соңгы 30 ел эчендә Кама алдында 31 процентка артты. Шулардан эрозиягә дучар ителгән сөрүлек җирләр мәйданы 27 процентка артты.

Туфракны һәм югары уңыш бирә торган агроландшафтны саклау өчен, экологик каркас рәвешендә 190 мең га. саклагыч урман, ягъни эрозиягә

каршы өстәмә тагын 100 мең га. агач утыртырга кирәк. Сөрүлек җирләрендә урман утыртуны оптималь 4,7–7 % дәрәҗәсенә җиткерер өчен, урман утыртуның хәзерге заман темпларын күз алдында тотып, 100 ел кирәк булачак.

Авыл хуҗалыгы факторының хайваннарга һәм аларның яшәү тирәлегенә югарыда аталган тискәре йогынтысына карамастан, авыл хуҗалыгы культуралары игелә торган кырлар күпчелек җәнлекләр өчен оя кору стацияләре ролен уйныйлар һәм саклагыч функция үтәп, ремизлар булып торалар. Моннан тыш, уңыш җыйганда котылгысыз югалтуларсыз булмый торган интенсив үсемлекчелек ау ресурсларының күпчелек төрләре өчен чагыштырмача ышанычлы һәм төрле азык базасы булдыра. Авыл хуҗалыгы культураларына зыян сала торган кимерүчеләр саны арта барганлыктан, агроценозлар ерткычлар өчен шулай ук азык нигезен формалаштыра. Җәйге-көзге чорда кыр кәҗәсе, кабан дуңгызы, соры куян, төлке, кыр тавыгы шикелле аучылык ресурслары авыл хуҗалыгы җирләренә өстенлек бирә.

2.3. Рекреация йогынтысы.

Аучылык хуҗалыгы өчен рекреация йогынтысы, башка факторлар белән бергә, аучылык ресурсларының яшәү тирәлеген характерлаучы бер фактор булып тора. Шул ук вакытта рекреация йогынтысының дәрәҗәсе аучылык биләмәләренең начараюына китерә торган фактор буларак кына түгел, бәлки хайваннарның яшәү тирәлегендә кешеләр тудырган уңайсызлыклар белән бәйле фактор буларак та карала.

Юллар челтәренең яхшы үскән, ә урманнарның аз булуы, алдынгы авыл хуҗалыгы, республика халкының күп санлы булуы нәтиҗәсендә, куркыту факторы төбәк өчен сизелерлек була һәм аучылык ресурсларына тискәре йогынты ясый.

Төбәк территориясендә, хайваннарны аулауга караганда да хәтта, куркыту факторы аларның санын күбрәк киметүгә китерә дип уйларга нигез бар. Аучылык биләмәләрендә күпсанлы кешеләр йөрүе хайваннарның тәүлеклек ритмын боза, аларда даими киеренкелек хисе уята. Кешенең аучылык биләмәләрендә йөрүе ояларын җирдә ясый торган кошларга иң зур зыян китерә. Оясыннан чыккан вакытта кыр үрдәге күкәйләрен мамык, үлән белән каплый, аннары зур саклык белән үлән арасыннан читкәрәк тайпылып, очып китә. Куркытылса, ул күкәйләрен капларга өлгерми, соңгыларын исә карга, янутсыман эт, төлке кебек ерткычлар бик тиз эзләп таба. Оясыннан еш очып чыгу күкәй басу режимы бозылуга һәм күкәйләрдәге бәбкәләрнең һәлак булуына китерә. Кошларның күпчелек төрләре, шул исәптән ау кошлары да, еш куркытып торсалар, ояларын бөтенләйгә ташлап китә. Яшь җәнлекләр тугач та беренче чорда аз хәрәкәтләнәләр, алардан эзләр дә азрак кала, шуңа күрә ерткычларга аларны табу кыеная. Куркытылган очракта, алар күбрәк хәрәкәт итәләр һәм үзләрен һәлакәткә дучар итәләр. Куркыту факторы тәэсирендә хайваннар күп вакытын үзләренең куркынычсызлыгын тәэмин итүгә сарыф итәләр, аларның туклану режимы бозыла, туклану урыннарыннан ерак китәләр, кеше йөрмәгән, азык аз җирләрдә тупланалар. Шулай итеп, куркыту факторы хайваннарның яшәеш ритмының бозылуына

китерә, аларда киеренкелек хисен уята, үз-үзләрен тотуларында һәм физиологияләрендә тайпылулар китереп чыгара, үрчү сәләтен киметә һәм яшь җәнлекләрнең үлеменә китерә.

2.4. Сузылган инженерлык объектларының йогынтысы

Сузылган инженерлык объектлары (су юллары, тимер юллар, газ- һәм нефтьүткәргечләр һ.б) тарафыннан ясалган коммуникатив антропоген йогынтының шактый зур өлеше йортлар салынган территорияләр урнашкан һәм нефть чыгару интенсив алып барыла торган урыннарда күзәтелә.

Электр үткәрү линияләрендә (ЭҮЛ), мәгълүматларга караганда кошларның 20 төренең үлеме күзәтелгән (күк карга, тилгән, көртлек карчыгасы, саз карчыгасы, карчыга, торымтай һ.б.). ЭҮЛның 1 километрына елына үлгән кошларның уртача унөче туры килә. Беренче чиратта яшь кошлар һәлак була, ЭҮЛның торак пунктларындагы өлешләре кошлар өчен аеруча куркыныч тудыра. Электр үткәрү линияләренең тимер-бетон баганаларында кошларның үлемен булдырмау өчен җайланмалар ясау зарур. Электр үткәрү линияләренең һавадагы өлешләрен проектлаштырганда, яңадан төзегәндә һәм эксплуатацияләгәндә (шул исәптән төзәткәндә, яңадан техник җиһазландырганда һәм реконструкцияләгәндә) кошлар тимерчыбыкка, траверса элементларына һәм баганаларга, ярдәмче трансформатор станцияләренә һ.б. кунганда, аларны ток сугып үтерүгә юл куймау чаралары күздә тотылырга тиеш.

Юллар, куе челтәр булып, бөтен республика территориясен каплаган. Автомобиль юлларында хайван-җанварлар, аеруча аларның балалары күпләп һәлак була. Аучылык төрләреннән, аеруча яшь җәнлек-җанвар күбәя торган җәйге-көзге чорда, төлкенең, соры һәм ак куянның саны кими.

2.5. Комплекслы антропоген йогынты.

Факторлар комплексында техноген йогынтыны тикшергәндә Арча, Саба, Балтач, Кукмара һәм Мамадыш районнарында аның төбәк буенча уртача күрсәткечләрдән югарырак, ә Балык Бистәсе, Биектау, Теләче, Питрәч һәм Зеленодольск районнарында түбәнрәк чагылуын билгеләп китәргә кирәк.

Антропоген йогынтының җирлек төрләренә турыдан-туры бәйләнеше ачык чагылыш тапмый, бу исә һәр җирдә кешенең табигый комплексларга йогынтысы белән аңлатыла. Иң зур басым субүлемнәргә, сөзәклекләрнең түбән өлешләренә һәм зур елгаларның түбәнге террасаларына туры килә. Субүлемнәргә йогынты транспорт комплексы ягыннан бара; сөзәклекләрнең түбән өлешләренә игенчелек алып бару һәм эрозиягә дучар ителгән җирләрнең үсеше йогынты ясый; зур елгаларның түбән террасаларына йогынты торак пунктлар урнашу белән бәйле.

Регионның аучылык фаунасына комплекслы йогынтыны анализлаганда, антропоген факторларның хайваннар дөньясына иң зур йогынты ясавын билгеләп китәргә кирәк. Шул ук вакытта, аерым уңай яклары булуга карамастан, тискәре йогынтысы күпкә артыграк. Өстәвенә, аерым антропоген факторларның тискәре йогынтысы соңгы елларда сизелерлек артты.

## 4. Татарстан Республикасында аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге булган аучылык биләмәләренең яки башка территорияләрнең урнашуы һәм алардан файдалану торышының сыйфатламасы

### 4.1. Аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге булган аучылык биләмәләренең яки башка территорияләрнең кемнеке булуы турында мәгълүмат

Татарстан Республикасының гомуми мәйданы 6 783 744 га тәшкил итә. Аңа аучылык ресурсларын файдалану өчен бүленгән 6 302 855 га мәйдандагы махсус территорияләр керә. Шулардан 490 181 га – аучылык хуҗалыгын алып бару өчен яраксыз, шул исәптән торак пунктлар, сәнәгый комплекслар, юл үткәргечләр, ә шулай ук рудераль җирләр (чүплекләр, зиратлар һ.б.) урнашкан территорияләр. Аучылык өчен файдаланылмый торган территорияләр мәйданы 45 719,46 га тәшкил итә, алар составында ау бөтенләй тыелган, аерым саклана торган табигать территорияләре бар: «Чатыр-Тау» төбәк дәрәҗәсендә әһәмияткә ия булган, комплекс профилендәге дәүләт табигать заказнигы, «Долгая поляна» төбәк дәрәҗәсендә әһәмияткә ия булган, комплекс профилендәге дәүләт табигать заказнигы, «Аю Урманы» төбәк дәрәҗәсендә әһәмияткә ия булган табигать һәйкәле, «Щучьи горы» төбәк дәрәҗәсендә әһәмияткә ия булган табигать һәйкәле, «Түбән Кама» милли паркы, Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы.

Төбәк территориясенең муниципаль берәмлекләр аучылык биләмәләренең мәйданы билгеләнгән структурасы турында гомуми мәгълүмат 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

Татарстан Республикасының административ бүленеше яссылыгында аучылык биләмәләре һәм башка территорияләрнең структурасы турында гомуми мәгълүмат

| Т/с | Район, шәһәр | Мәйданы, мең га | Аучылык өчен файдаланылмый торган территорияләр, мең га | Аучылык ресурсларын файдалану максаты өчен бирелгән территорияләр | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Гомуми мәйдан | | | | Беркетелгән аучылык биләмәләре | | Һәркем файдалана алырлык аучылык биләмәләре | |
| | | | | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % | Аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге, мең га | Аучылык хуҗалыгын алып барырга яраксыз, мең га | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % |
| 1 | Әгерҗе | 179,662 | 0 | 172,211 | 95,85 | 172,54 | 7,451 | 95,2 | 52,99 | 77,011 | 42,86 |
| 2 | Азнакай | 214,611 | 4,1495 | 201,543 | 93,91 | 198,838 | 13,068 | 60,47 | 28,18 | 141,073 | 65,73 |
| 3 | Аксубай | 143,916 | 0 | 136,095 | 94,57 | 136,684 | 7,821 | 90,3 | 62,74 | 45,795 | 31,82 |
| 4 | Актаныш | 203,4 | 0 | 203,4 | 100,00 | 196,82 | 0 | 203,4 | 100 | 0 | 0,00 |
| 5 | Алексеевск | 207,441 | 0 | 199,176 | 96,02 | 199,548 | 8,265 | 110,897 | 53,46 | 88,279 | 42,56 |
| 6 | Әлки | 172,676 | 0 | 165,911 | 96,08 | 166,094 | 6,765 | 20,274 | 11,74 | 145,637 | 84,34 |
| 7 | Әлмәт | 242,794 | 0 | 222,783 | 91,76 | 225,247 | 20,011 | 200,662 | 82,65 | 22,121 | 9,11 |
| 8 | Апас | 104,752 | 0 | 99,4 | 94,89 | 93,23 | 5,352 | 99,4 | 94,89 | 0 | 0,00 |
| 9 | Арча | 184,365 | 0,4162 | 173,429 | 94,07 | 173,607 | 10,936 | 139,165 | 75,48 | 34,264 | 18,58 |
| 10 | Әтнә | 68,136 | 0 | 68,136 | 100,00 | 64,749 | 0 | 68,136 | 100 | 0 | 0,00 |

| Т/с | Район, шәһәр | Мәйданы, мең га | Аучылык өчен файдаланылмый торган территорияләр, мең га | Аучылык ресурсларын файдалану максаты өчен бирелгән территорияләр | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Гомуми мәйдан | | | | Беркетелгән аучылык биләмәләре | | Һәркем файдалана алырлык аучылык биләмәләре | |
| | | | | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % | Аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге, мең га | Аучылык хуҗалыгын алып барырга яраксыз, мең га | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % |
| 11 | Бавлы | 120,466 | 0 | 113,198 | 93,97 | 113,785 | 7,268 | 20,53 | 17,04 | 92,668 | 76,92 |
| 12 | Балтач | 109,45 | 0 | 109,419 | 99,97 | 103,743 | 0,031 | 45,119 | 41,22 | 64,3 | 58,75 |
| 13 | Бөгелмә | 140,52 | 0 | 130,043 | 92,54 | 131,299 | 10,477 | 115,1 | 81,91 | 14,943 | 10,63 |
| 14 | Буа | 152,845 | 0 | 153,447 | 100,39 | 144,017 | 0 | 153,447 | 100 | 0 | 0,00 |
| 15 | Югары Ослан | 130,282 | 0 | 117,695 | 90,34 | 122,446 | 12,587 | 93,995 | 72,15 | 23,7 | 18,19 |
| 16 | Биектау | 157,425 | 0 | 146,512 | 93,07 | 148,05 | 10,913 | 144,33 | 91,68 | 2,182 | 1,39 |
| 17 | Чүпрәле | 102,954 | 0 | 93,267 | 90,59 | 94,397 | 9,687 | 17,3 | 16,80 | 75,967 | 73,79 |
| 18 | Алабуга | 135,229 | 17,701 | 106,779 | 78,96 | 108,705 | 28,45005 | 96,2 | 71,14 | 10,579 | 7,82 |
| 19 | Зәй | 184,24 | 0 | 175,967 | 95,51 | 176,912 | 8,273 | 175,967 | 95,51 | 0 | 0,00 |
| 20 | Зеленодольск | 140,199 | 5,921 | 129,177 | 92,14 | 123,4 | 11,022 | 122,75 | 87,55 | 6,427 | 4,58 |
| 21 | Кайбыч | 99,536 | 0 | 95,061 | 95,50 | 95,802 | 4,475 | 78,012 | 78,38 | 17,049 | 17,13 |
| 22 | Кама Тамагы | 119,88 | 0 | 113,72 | 94,86 | 111,383 | 6,16 | 107,894 | 90,00 | 5,826 | 4,86 |

| Т/с | Район, шәһәр | Мәйданы, мең га | Аучылык өчен файдаланылмый торган территорияләр, мең га | Аучылык ресурсларын файдалану максаты өчен бирелгән территорияләр | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Гомуми мәйдан | | | | Беркетелгән аучылык биләмәләре | | Һәркем файдалана алырлык аучылык биләмәләре | |
| | | | | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % | Аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге, мең га | Аучылык хуҗалыгын алып барырга яраксыз, мең га | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % |
| 23 | Кукмара | 149 | 0 | 149,209 | 100,14 | 138,149 | 0 | 149,209 | 100 | 0 | 0,00 |
| 24 | Лаеш | 209,443 | 4,17 | 180,915 | 86,38 | 189,834 | 28,528 | 136,341 | 65,10 | 44,574 | 21,28 |
| 25 | Лениногорск | 181,272 | 0 | 168,097 | 92,73 | 170,902 | 13,175 | 151,5 | 83,58 | 16,597 | 9,16 |
| 26 | Мамадыш | 261,252 | 0 | 252,457 | 96,63 | 252,866 | 8,795 | 205,19 | 78,54 | 47,267 | 18,09 |
| 27 | Менделеевск | 74,49 | 0 | 74,6 | 100,15 | 68,984 | 0 | 0 | 0,00 | 74,6 | 100 |
| 28 | Минзәлә | 191,975 | 0 | 187,8 | 97,83 | 186,004 | 4,175 | 187,8 | 97,83 | 0 | 0,00 |
| 29 | Мөслим | 146,431 | 0 | 141,149 | 96,39 | 141,899 | 5,282 | 92,975 | 63,49 | 48,174 | 32,90 |
| 30 | Түбән Кама | 161,715 | 0 | 151,0551 | 93,41 | 152,867 | 10,65988 | 141,6 | 87,56 | 9,455 | 5,85 |
| 31 | Яңа Чишмә | 131,752 | 0 | 124,37 | 94,40 | 125,337 | 7,382 | 53,8 | 40,83 | 70,57 | 53,56 |
| 32 | Нурлат | 229,371 | 0 | 219,997 | 95,91 | 221,52 | 9,374 | 59,2 | 25,81 | 160,797 | 70,10 |
| 33 | Питрәч | 133,954 | 0 | 130,75 | 97,61 | 125,949 | 3,204 | 98,45 | 73,50 | 32,3 | 24,11 |
| 34 | Балык Бистәсе | 204,141 | 0 | 195,864 | 95,95 | 196,62 | 8,277 | 54,569 | 26,73 | 141,295 | 69,21 |

| Т/с | Район, шәһәр | Мәйданы, мең га | Аучылык өчен файдаланылмый торган территорияләр, мең га | Аучылык ресурсларын файдалану максаты өчен бирелгән территорияләр | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Гомуми мәйдан | | | | Беркетелгән аучылык биләмәләре | | Һәркем файдалана алырлык аучылык биләмәләре | |
| | | | | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % | Аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге, мең га | Аучылык хуҗалыгын алып барырга яраксыз, мең га | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % | Барлыгы, мең га | Район мәйданыннан өлеше, % |
| 35 | Саба | 109,774 | 0 | 118,1445 | 107,63 | 102,963 | 0 | 112,0475 | 102,07 | 6,097 | 5,55 |
| 36 | Сарман | 138,556 | 0 | 129,505 | 93,47 | 129,93 | 9,051 | 43,5 | 31,40 | 86,005 | 62,07 |
| 37 | Спас | 202,214 | 0 | 194,417 | 96,14 | 195,308 | 7,797 | 99,87 | 49,39 | 94,547 | 46,76 |
| 38 | Тәтеш | 163,842 | 4,41076 | 157,435 | 96,09 | 154,712 | 6,407 | 123,252 | 75,23 | 34,183 | 20,86 |
| 39 | Тукай | 172,949 | 8,951 | 151,1609 | 87,40 | 154,126 | 21,7881 | 77,717 | 44,94 | 73,444 | 42,47 |
| 40 | Теләче | 84,408 | 0 | 80,848 | 95,78 | 81,246 | 3,56 | 26,81 | 31,76 | 54,038 | 64,02 |
| 41 | Чирмешән | 136,428 | 0 | 128,155 | 93,94 | 128,766 | 8,273 | 62,138 | 45,55 | 66,017 | 48,39 |
| 42 | Чистай | 176,567 | 0 | 168,147 | 95,23 | 168,638 | 8,42 | 74,05 | 41,94 | 94,097 | 53,29 |
| 43 | Ютазы | 76,057 | 0 | 72,41 | 95,20 | 69,876 | 3,647 | 0 | 0,00 | 72,41 | 95,20 |
| 44 | Азнакай | 2,254 | - | - | - | - | 2,254 | - | - | - | - |
| 45 | Әлмәт | 11,499 | - | - | - | - | 11,499 | - | - | - | - |
| 46 | Бөгелмә | 2,787 | - | - | - | - | 2,787 | - | - | - | - |

| 9 | Үзгәртелгән һәм зарар күргән участоклар | Үзгәртелгән һәм зарар күргән участоклар (янган урманнар, торф чыгару урыннары, җилдән ышыклау валлары һ.б.) | 0 | 0 | 72 | 0 | 16 | 0 | 0 |
| 10 | Аучылык хуҗалыгы алып барырга яраксыз | Сәнәгать һәм рудераль комплекслар, торак пунктлар һ.б. | 8309 | 12551 | 9878 | 10874 | 9860 | 15196 | 5700 |
| Районнар мәйданы барлыгы | | | 130280,22688 | 157426,9342 | 102953,54914 | 140142,605345 | 190079,0835 | 143972,22282 | 99536,4356 |
| Яр сызыгының озынлыгы | | | 587,52677 | 691,57606 | 354,02050 | 958,72783 | 603,72322 | 607,26642 | 391,48656 |

10 нчы таблицаның дәвамы

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Кама Тамагы | Кукмара | Лаеш | Ленино-горск | Мамадыш | Менде-леевск | Минзәлә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Урманнар | Мәңге яшел ылыслы (мәңге яшел ылыслы токымнар 80 % артык) | 0 | 0 | 0 | 0 | 3673 | 984 | 55 |
| | | Вак яфраклы (вак яфраклы токымнар 80 % артык ) | 0 | 0 | 150 | 6948 | 4365 | 0 | 580 |
| | | Киң яфраклы (киң яфраклы токымнар 30 % артык) | 0 | 0 | 5809 | 29450 | 2904 | 0 | 260 |
| | | Ылыслы токымнар өстенлек иткән катнаш (ылыслы токымнар 60–80 %) | 0 | 7219 | 9527 | 0 | 12307 | 3112 | 3 |
| | | Вак яфраклы токымнар өстенлек иткән катнаш (вак яфраклы токымнар 60–80 %) | 1986 | 10728 | 3457 | 15596 | 51482 | 913 | 17538 |
| | | Киң яфраклы | 8502 | 12326 | 15081 | 1178 | 317 | 162 | 3339 |

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Кама Тамагы | Кукмара | Лаеш | Ленино-горск | Мамадыш | Менде-леевск | Минзәлә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | токымнар булган катнаш (киң яфраклы токымнар 30 % ким) | | | | | | | |
| 2 | Яшь үсемлекләр һәм куаклар | Кисентеләр һәм үлән баскан кырлар | 0 | 0 | 0 | 0 | 43 | 0 | 18 |
| | | Яфраклы куаклар | 1189 | 412 | 890 | 163 | 1905 | 21 | 3238 |
| 3 | Сазлыклар | Үләнле | 0 | 0 | 432 | 0 | 96 | 0 | 917 |
| 4 | Болын-дала комплекслары | Болыннар | 89 | 331 | 1745 | 161 | 3941 | 0 | 161 |
| 5 | Авыл хуҗалыгы биләмәләре | Сөрү җирләре | 67357 | 99388 | 83080 | 106768 | 124739 | 50756 | 107803 |
| | | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге болыннар (печәнлекләр һәм көтүлекләр) | 9791 | 6766 | 8705 | 12494 | 18616 | 4395 | 9992 |
| 6 | Эчке су объектлары | Эре агым сулар | 53,76372 | 371,7532 | 260,9337 | 317,3442 | 3844,749 | 156,0183 | 443,252 |
| | | Уртача агым сулар | 172,5407 | 220,7579 | 44,54945 | 198,9291 | 347,3205 | 82,07108 | 120,3136 |
| | | Кечкенә агым сулар | 85,25298 | 122,4488 | 59,26907 | 159,0293 | 192,4914 | 43,34852 | 119,7941 |

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Кама Тамагы | Кукмара | Лаеш | Ленино-горск | Мамадыш | Менде-леевск | Минзәлә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сусаклагычлар | 24886 | 0 | 65362 | 0 | 7893 | 9377 | 21404 |
| | | Күлләр, бөяләр | 84 | 276 | 169 | 149 | 1821 | 55 | 2018 |
| 7 | Тугайлык комплекслары | Үләннәр өстенлек иткән (урман һәм куаклар 20 % кадәр) | 0 | 12 | 261 | 0 | 4969 | 0 | 3353 |
| 8 | Яр комплекслары | Эчке су объектларының яр комплексы | 21 | 0 | 3386 | 0 | 5349 | 7 | 14021 |
| 9 | Үзгәртелгән һәм зарар күргән участоклар | Үзгәртелгән һәм зарар күргән участоклар (янган урманнар, торф чыгару урыннары, җилдән ышыклау валлары һ.б.) | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 10 | Аучылык хуҗалыгы алып барырга яраксыз | Сәнәгать һәм рудераль комплекслар, торак пунктлар һ.б. | 5664 | 10827 | 11024 | 10740 | 12447 | 4427 | 6590 |
| Районнар мәйданы барлыгы | | | 119880,5574 | 148999,9599 | 209442,75222 | 184322,3026 | 261251,5609 | 74490,4379 | 191973,3597 |
| Яр сызыгының озынлыгы | | | 333,38032 | 541,14461 | 272,44670 | 610,80650 | 1160,2325 | 203,82927 | 504,79786 |

10 нчы таблицаның дәвамы

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Мөслим | Түбән Кама | Яңа Чишмә | Норлат | Питрәч | Балык Бистәсе | Саба |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Урманнар | Мәңге яшел ылыслы (мәңге яшел ылыслы токымнар 80 % артык) | 0 | 0 | 0 | 465 | 0 | 9098 | 0 |
| | | Вак яфраклы (вак яфраклы токымнар 80 % артык) | 143 | 0 | 0 | 5292 | 181 | 217 | 0 |
| | | Киң яфраклы (киң яфраклы токымнар 30 % артык) | 9609 | 1413 | 0 | 0 | 4267 | 8185 | 0 |
| | | Ылыслы токымнар өстенлек иткән катнаш (ылыслы токымнар 60–80 %) | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 7580 | 17979 |
| | | Вак яфраклы токымнар өстенлек иткән катнаш (вак яфраклы токымнар 60–80 %) | 17993 | 43862 | 13900 | 40970 | 71 | 8482 | 430 |

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Мөслим | Түбән Кама | Яңа Чишмә | Норлат | Питрәч | Балык Бистәсе | Саба |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Киң яфраклы токымнар булган катнаш (киң яфраклы токымнар 30 % ким) | 21 | 0 | 0 | 50504 | 13221 | 18436 | 8629 |
| 2 | Яшь үсемлекләр һәм куаклар | Кисентеләр һәм үлән баскан кырлар | 0 | 41 | 0 | 23 | 4 | 15 | 23 |
| | | Яфраклы куаклар | 1372 | 3071 | 551 | 1045 | 521 | 1346 | 27 |
| 3 | Сазлыклар | Үләнле | 50 | 335 | 0 | 0 | 0 | 24 | 0 |
| 4 | Болын-дала комплекслары | Болыннар | 105 | 1995 | 89 | 2929 | 225 | 563 | 65 |
| 5 | Авыл хуҗалыгы биләмәләре | Сөрү җирләре | 101707 | 95055 | 55283 | 98502 | 90178 | 98245 | 68370 |
| | | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге болыннар (печәнлекләр һәм көтүлекләр) | 4471 | 14578 | 5149 | 11954 | 15892 | 15575 | 6214 |
| 6 | Эчке су объектлары | Эре агым сулар | 428,2235 | 2644,161 | 311,5052 | 690,3954 | 352,3624 | 165,3951 | 99,62301 |
| | | Уртача агым сулар | 150,8792 | 183,932 | 151,3443 | 187,4593 | 93,42869 | 268,2594 | 162,7278 |

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Мөслим | Түбән Кама | Яңа Чишмә | Норлат | Питрәч | Балык Бистәсе | Саба |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Кечкенә агым сулар | 114,8972 | 110,6654 | 63,82032 | 135,2938 | 140,2116 | 132,7176 | 78,67842 |
| | | Сусаклагычлар | 0 | 2999 | 0 | 3583 | 0 | 23335 | 0 |
| | | Күлләр, бөяләр | 652 | 1251 | 180 | 800 | 398 | 475 | 80 |
| 7 | Тугайлык комплекслары | Үләннәр өстенлек иткән (урман һәм куаклар 20 % кадәр) | 3363 | 1438 | 5721 | 1901 | 0 | 0 | 0 |
| 8 | Яр комплекслары | Эчке су объектларының яр комплексы | 0 | 3724 | 0 | 0 | 0 | 2750 | 0 |
| 9 | Үзгәртелгән һәм зарар күргән участоклар | Үзгәртелгән һәм зарар күргән участоклар (янган урманнар, торф чыгару урыннары, җилдән ышыклау валлары һ.б.) | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 10 | Аучылык хуҗалыгы алып барырга яраксыз | Сәнәгать һәм рудераль комплекслар, торак пунктлар һ.б. | 6251 | 16743 | 50352 | 11914 | 8410 | 9249 | 7617 |

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Мөслим | Түбән Кама | Яңа Чишмә | Норлат | Питрәч | Балык Бистәсе | Саба |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Районнар мәйданы барлыгы | | | 146430,9999 | 189443,7584 | 131751,66982 | 230895,1485 | 133954,00269 | 204141,3721 | 109775,02923 |
| Яр сызыгының озынлыгы | | | 507,07820 | 1019,82566 | 356,70703 | 702,43034 | 475,21359 | 561,81986 | 320,03512 |

10 нчы таблицаның дәвамы

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Сарман | Спас | Тәтеш | Тукай | Теләче | Чирмешән | Чистай | Ютазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Урманнар | Мәңге яшел ылыслы (мәңге яшел ылыслы токымнар 80 % артык) | 0 | 312 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | | Вак яфраклы (вак яфраклы токымнар 80 % артык) | 0 | 2786 | 0 | 778 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | | Киң яфраклы (киң яфраклы токымнар 30 % артык) | 422 | 0 | 23274 | 0 | 0 | 9531 | 0 | 0 |
| | | Ылыслы токымнар өстенлек иткән | 0 | 5238 | 0 | 0 | 2412 | 0 | 0 | 0 |

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Сарман | Спас | Тәтеш | Тукай | Теләче | Чирмешән | Чистай | Ютазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | катнаш (ылыслы токымнар 60–80 %) | | | | | | | | |
| | | Вак яфраклы токымнар өстенлек иткән катнаш (вак яфраклы токымнар 60–80 %) | 8265 | 1675 | 0 | 21431 | 6681 | 24972 | 6637 | 7709 |
| | | Киң яфраклы токымнар булган катнаш (киң яфраклы токымнар 30 % ким) | 4 | 9160 | 4237 | 1723 | 3329 | 1629 | 6174 | 887 |
| 2 | Яшь үсемлекләр һәм куаклар | Кисентеләр һәм үлән баскан кырлар | 0 | 0 | 0 | 11 | 10 | 0 | 0 | 0 |
| | | Яфраклы куаклар | 48 | 789 | 97 | 189 | 376 | 140 | 107 | 425 |
| 3 | Сазлыклар | Үләнле | 0 | 208 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4 | Болын-дала комплекслары | Болыннар | 44 | 385 | 149 | 252 | 12 | 0 | 83 | 132 |
| 5 | Авыл хуҗалыгы биләмәләре | Сөрү җирләре | 118529 | 110605 | 97166 | 78075 | 58320 | 87403 | 125419 | 57212 |
| | | Авыл хуҗалыгы | 2529 | 9545 | 8133 | 6629 | 6930 | 4574 | 9176 | 4192 |

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Сарман | Спас | Тәтеш | Тукай | Теләче | Чирмешән | Чистай | Ютазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | билгеләнешендәге болыннар (печәнлекләр һәм көтүлекләр) | | | | | | | | |
| 6 | Эчке су объектлары | Эре агым сулар | 187,6959 | 74,0197 9 | 144,2298 | 1152,668 | 165,0408 | 206,8892 | 116,0009 | 160,0972 |
| | | Уртача агым сулар | 103,7759 | 65,6807 7 | 217,6933 | 216,1504 | 120,2479 | 101,4853 | 199,0016 | 99,60204 |
| | | Кечкенә агым сулар | 94,705 | 23,5182 8 | 127,3865 | 165,2427 | 81,71515 | 119,0381 | 63,62324 | 44,76307 |
| | | Сусаклагычлар | 0 | 49638 | 21638 | 30448 | 0 | 0 | 15342 | 0 |
| | | Күлләр, бөяләр | 386 | 1196 | 167 | 1084 | 157 | 428 | 924 | 535 |
| 7 | Тугайлык комплекслары | Үләннәр өстенлек иткән (урман һәм куаклар 20 % кадәр) | 0 | 42 | 44 | 151 | 232 | 458 | 0 | 677 |
| 8 | Яр комплекслары | Эчке су объектларының яр комплексы | 0 | 4314 | 17 | 1473 | 0 | 0 | 7406 | 0 |
| 9 | Үзгәртелгән һәм | Үзгәртелгән һәм | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Сарман | Спас | Тәтеш | Тукай | Теләче | Чирмешән | Чистай | Ютазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | зарар күргән участоклар | зарар күргән участоклар (янган урманнар, торф чыгару урыннары, җилдән ышыклау валлары һ.б.) | | | | | | | | |
| 10 | Аучылык хуҗалыгы алып барырга яраксыз | Сәнәгать һәм рудераль комплекслар, торак пунктлар һ.б. | 7942 | 6158 | 8431 | 29171 | 5584 | 6866 | 10179 | 3983 |
| Барлыгы районнар мәйданы | | | 138555,1768 | 202214,21884 | 163842,3096 | 172949,0611 | 84410,00385 | 136428,4126 | 181825,62574 | 76056,46231 |
| Яр сызыгының озынлыгы | | | 371,56213 | 136,44071 | 468,56258 | 610,80082 | 331,03744 | 380,16384 | 332,9265 | 216,9430 |

2. Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурслары яшәү тирәлеге элементлары сыйфатына комплекслы бәяләмә (бонитировка).

2.1. Гомуми мәгълүмат һәм методик нигезләмә.

Бонитировка – ул аучылык биләмәләре сыйфатының гомумиләштергән бәяләмәсе. Биләмәләрнең кыйммәте беренче чиратта үлән катламының нинди булуына бәйле рәвештә, аны азык буларак куллану, саклану һәм оя ясарга яраклы булу кебек сыйфатлар белән билгеләнә. Әлеге сыйфатларга шулай ук әйләнә-тирәнең төрле факторлары йогынты ясый: климат, кеше эшчәнлеге, конкурентлык, ерткычлар йогынтысы, авыруларның күпләп таралуы һ.б. Территориягә хуҗалык ягыннан бәя биргәндә, әйләнә-тирәнең бөтен факторлары җыелмасын һәм аларның үзара йогынтысын исәпкә алырга кирәк.

Әйләнә-тирә факторлары теге яки бу дәрәҗәдә үсемлекләрнең һәм биләмәләрнең төрләренә бәйле. Шулай итеп, хайваннарга һәм кошларга гомумән төбәк климаты гына түгел, ә алар өчен яшәү тирәлеге булып торган үсемлекләрнең фитоклиматы да тәэсир итә. Үсемлекләр төре генә түгел, ә территорияне хуҗалык ягыннан файдалану (печән чабу, терлекләр көтү, гөмбә, җиләк җыю һ.б.) да фаунага йогынты ясый. Конкурентлар, ерткычлар һәм корбаннар арасындагы мөнәсәбәтләр төрле биләмәләрдә төрлечә киеренкелеккә ия була.

Нинди дә булса төргә караган биләмәләр бер-берсенә охшамаган, шуңа да аларны ким дигәндә өч категориягә аеру кыен түгел: яхшы, уртача һәм начар. Аучылык практикасында шулай ук ике арадаш категория – уртачадан түбәнрәк һәм уртачадан югарырак бар.

Яхшы биләмәләр – ул аучылык ресурсларының әлеге төре өчен төп яшәү урыны. Алар саклау үзлекләренең югары дәрәҗәсе, ел саен мул, төрле һәм тотрыклы азык базасы булу белән аерылып тора. Бу пессимум елларында аучылык ресурсларының яшәү урыны. Яхшы биләмәләрдә, кагыйдә буларак, башка категория биләмәләргә караганда күбрәк яшиләр. Аларда хуҗалыкта яшәүче әлеге төрнең баш санының төп өлеше туплана. Яхшы биләмәләрдә хайваннар кеше ярдәменнән башка да әйбәт яши. Иң яхшы биләмәләр төп биләмәләр дип атала.

Начар биләмәләр капма-каршы сыйфатлар белән характерлана. Аларда азык аз, саклану өчен шартлар начар. Бу яшәү урыннары аучылык ресурсларының әлеге төренә хас түгел, биредә хайваннар аз яисә очраклы гына яши. Бу категориядәге биләмәләр аучылык ресурслары төрләре таралышында мөһим роль уйнамый. Биотехник чаралар монда нәтиҗәле түгел.

Уртача биләмәләр бөтен күрсәткечләре буенча арадаш категориягә керә. Азык базасы аларда составы ягыннан бертөрле, азыкларны җыеп алу сирәгрәк һәм күләме буенча зур түгел, саклану өчен шартлар начар. Хайваннарның яшәве еллар буенча тигез түгел һәм бик аз. Кешенең, әйләнә-тирәнең тискәре факторлары йогынтысын бетерү яки йомшартуга юнәлтелгән биотехник йогынтысы нәтиҗәсендә, аучылык ресурслары саны шактый артырга мөмкин.

Биләмәләр төрләре өчен хас булган гомумиләштерелгән уртача бәяне, һәрбер категориягә туры килә торган биләмәләрнең мәйданына туры килә торган санга тапкырлап, сумманы биләмәләргә хас булган гомуми мәйданга кушып һәм бүлеп

алалар (11 нче таблица). Алга таба табылган санның бонитетның кайсы классы чикләрендә булуын билгелиләр. Әгәр дә тирәлекнең кайсы да булса элементы әлеге төрнең санына тискәре һәм каты тәэсир итсә, ул чакта урнашучы территориянең бонитеты бер-ике класска түбәнәя. Мәсәлән, төрнең санына климат шартлары тискәре тәэсир итсә, бу территориянең бонитеты бер-ике класска түбәнәя. Шулай итеп, әлеге төр өчен критик зурлыкны тәшкил итүче кар капламының тирәнлеге, поши, болан, Кабан дуңгызы, соры куян һәм соры кыр тавыгы яши торган тирәлекнең составы һәм сыйфаты буенча саналган бонитетны бер класска төшерә, ягъни I дән II гә, II дән III кадәр, ә кыр кәҗәсе өчен – ике класска, ягъни I дән III кадәр, II дән IV кадәр.

11 нче таблица

Төрле класс бонитетлары өчен биләмәләрнең җитештерүчәнлек күрсәткечләре нисбәте

| Бонитет классы | Биләмәләрнең терминологик бәяләмәсе | III бонитет күрсәткечләреннән җитештерүчәнлек күрсәткечләре, % | |
|---|---|---|---|
| | | уртача | чик |
| I | Яхшы | 250 | >200 |
| II | Уртачадан югары | 165 | 200-130 |
| III | Уртача | 100 | 130-70 |
| IV | Уртачадан түбән | 50 | 70-30 |
| V | Начар | 15 | <30 |

Татарстан Республикасында аучылык ресурслары яшәү тирәлеге элементларына бәя бирү аеруча кыйммәтле аучылык ресурслары өчен уздырылды.

Поши.

Типик урман хайваны. Шуңа да бу төр өчен территориягә бәя биргәндә эре массивлар буларак урнашкан урман биләмәләре алына һәм исәпләү өчен урман һәм урман сазлыгы мәйданнары, шулай ук үлән белән капланып килүче буш урыннар һәм тал куаклыклары алына. Поши яшәү өчен яхшы биләмәләр категориясенә түбәндәгеләр керә: составында нарат һәм усак булган яшь агачлыклар, тал, эт шомырты, артыш куаклыклары һәм куе үлән катламы булган тал, шомырт, эт шомырты куаклыклары, шулай ук нарат, усак, тал, миләш һәм агачларның азык буларак кулланыла торган башка төрләре үсеп килә торган кисентеләр һәм янган урман урыннары. Уртача биләмәләр категориясенә яшь нарат һәм усак агачлары, тал, артыш, эт шомырты һәм кабар куаклыклары һәм куе үлән катламы үскән карт һәм урта яшьтәге урманнар, ә шулай ук каен һәм чыршы, нарат һәм усак өстенлек иткән, яшь агачлар һәм үлән капламы күп булган яшь агачлыклар. Начар биләмәләр категориясенә түбәндәгеләрне кертәләр: үсеп килә торган яшь агачлары булмаган яисә чыршыдан гына торган агачлыклар яки куаклыклар булмаган һәм төрле үлән

капламлы карт урманнар, шулай ук куаклыкларсыз һәм үлән катламсыз, шулай ук тыгыз утыртылган каен, чыршы һәм зирек урманнары һәм куе утыртылган урта яшьтәге ботакларсыз агачлар.

Себер кыр кәҗәсе.

Себер кыр кәҗәсе торырга яраклы урманнар һәм ачык җирләр, зур күлләрнең су өслегеннән кала, бәяләнә. Себер кыр кәҗәсе өчен яхшы биләмәләр булып куе яфраклы яшь агачлар үсеп килә торган, төрле үләннәр үсүче болынлы һәм аланлы урман биләмәләре (ботаксыз агачлар һәм җитлеккән наратлыклардан кала) тора. Әлеге категориягә тал куаклыклары һәм төрле үләннәр үскән елга үзәннәрен кертергә була. Уртача биләмәләр категориясенә яшь үсентеле һәм аз гына өлешен урман аланнары һәм болыннары биләп торган уртача яшьтәге һәм җитлеккән урманнар керә. Бу категориягә камыш һәм тал куаклары үскән сазлыкларны һәм уйсулыкларны, яшь үсентеле буразналап утыртылган уртача куелыктагы каен-усак урманнарын кертергә була. Себер кыр кәҗәсе өчен начар биләмәләр – яшь үсентеләре булмаган, үләм капламы аз булган урман биләмәләренең барлык төрләре. Әлеге категориягә шулай ук кышын аларның азык һәм саклану ягыннан әһәмиятеннән чыгып, барлык төр кырлар (сөрүлекләр, көтүлекләр һ.б.) кертелә.

Кабан дуңгызы.

Кабан дуңгызы өчен территориягә бәя биргәндә, урманнар гына түгел, ә алардан 0,5 км ераклыкта урнашкан ачыклык җирләрне дә кертәләр. Кабан дуңгызы өчен яхшы биләмәләргә имән, яшь чыршы үскән, урман чикләвеге һәм артыш куаклыклары, кырлыган, кара абага, бүре җиләге, җил үләне һәм аерым өлешләрендә камыш һәм кычыткан үскән җитлеккән урманлыклар керә. Шулай ук яхшы биләмәләр категориясенә сазланган яфраклы-ылыслы урманнар (сфагнум мүгеннән кала) керә.

Уртача биләмәләр категориясенә яшел мүкле һәм озын мүкле төркемнәргә караган яфраклы, ылыслы һәм катнаш (имәнсез) карт урманнар, шулай ук тыгыз утыртылган яшь нарат һәм чыршы агачлары керә. Җитлеккән урманнарда чыршы һәм артыш агачларының яшь үсентеләре булырга тиеш. Уртача биләмәләр категориясенә шулай ук урманга якын торучы болыннар, печәнлекләр һәм кыяклы сазлыклар керә.

Начар биләмәләр категориясенә коры урында урнашкан, яшь үсентеләр, куаклыклар һәм аз төрдәге үлән катламлы, шулай ук сфанг мүкле сазлыклар керә.

Ак куян.

Урманда даими яшәүче җәнлек. Аның өчен территорияне бәяләгәндә бары тик урманнар гына карала. Куян яшәү өчен яхшы биләмәләр категориясенә чыршы, усак, корычагач, каен һәм чыршы, тал, кабар агачы, артыш үсентеләре һәм күрән һәм кыяклы ашлыклар капламы булган бөтен яшьтәге катнаш урманнар керә.

Уртача биләмәләр категориясенә чыршылар булмаган, яфраклы агачларның үсентеләре сирәк яки бөтенләй булмаган, кара җиләк һәм арчан капламлы карт һәм яшь урманнар керә.

Начар биләмәләргә агачларның тамырлары тыгыз булу сәбәпле үсентеләре булмаган яисә ярлы һәм сазлыклы туфракта үскән урманнар керә.

Соры куян, соры кыр тавыгы.

Соры куян һәм соры кыр тавыгының типик яшәү урыннары булып ачык (дала, кыр, болын) биләмәләр һәм аларга тоташып үсүче 0,5 км кадәр киңлектәге урман участоклары тора.

Әлеге ике төр өчен яхшы биләмәләр категориясенә түбәндәгеләрне кертү зарур:

а) сөрер өчен уңайсыз, чокырлар, текә сөзәклекләр, кура, яфраклы һәм ылыслы яшь агачлар һәм үләннәр белән капланган сазлыкларның яр кырыйлары;

б) кура, куаклыклар, яшь урман участоклары белән аралашып килүче күп төрле кыяклы ашлык культуралары (күбрәк уҗым арышы) үсә торган кечкенә мәйдандагы (25 гектарга кадәр) кырлар;

в) биек үләнле, кура, куаклыклар булган дала һәм кырлар.

Уртача биләмәләр категориясенә түбәндәгеләр керә:

а) вак урманнар, куаклыклар, куралар белән бүленгән зур мәйдандагы (100 га кадәр) авыл хуҗалыгы культуралары кырлары;

б) тал һәм камыш үсә торган кыяклы сазлыклар;

в) кырларга тоташкан яфраклы һәм ылыслы яшь агачлыклар;

г) күпьеллык үләннәр чәчү өчен файдаланыла торган мәйданнар.

Начар биләмәләр категориясенә түбәндәгеләр керә:

а) вак урманнар, ызаннар, куаклыклар, чүп үләннәре участоклары булмаган зур мәйдандагы авыл хуҗалыгы культуралары кырлары;

б) үлән капламы начар үсә торган комлы яки сазлыклы туфраклы мәйданнар;

в) ачык урыннарга тоташкан куе карт урманнар.

Янутсыман эт.

Янутсыман эт өчен иң яхшы биләмәләр булып сазлыклы уйсулыкларга барып тоташучы сулыклары күп булган дымлы болыннар. Әлеге биләмәләр белән еш кына елга тугайлары һәм әрәмәлекләр чикләшә. Бу җирлек саклану өчен яхшы урын булуы белән аерылып тора һәм елның күпчелек вакытында азык белән яхшы тәэмин итешә. Янутсыман эт өчен яхшы биләмәләргә шулай ук авыл хуҗалыгы биләмәләре керә – урманнар, елгалар һәм сазлыклар белән чиктәш кырлар, печәнлекләр, кысыр җирләр, көтүлекләр керә. Әһәмияте азрак булган җирләргә – авыл хуҗалыгы җирләре белән аралаш яңа гына киселгән урман урынына утыртылган киң яфраклы урманнар керә. Куе ылыслы урманнарны җәнлек яратмый. Башка төр яшәү урыннары бу җәнлек өчен икенчел әһәмияткә ия.

Америка чәшкесе.

Америка чәшкесе сулыклар ярларының агачлар, куаклыклар ауган, тамырлар чыгып торган, су белән юылган участокларында яши. Чыбык-чабык ауган кечкенә урман елгаларын сайлый. Өемнәр арасында җәнлек үзенә яшеренер өчен ышанычлы урын таба.

Республикада чәшкегә яшәү өчен аеруча яхшы биләмәләр булып бай ихтиофауналы, төрле җир-су хайваннары, амфибияләр, кысласыманнар яши торган, агачлар һәм куаклыклар белән капланган текә ярлы, киң үзәнле, чүп-чар белән тулган, күп санлы ермак, күл һәм иске үзәннәре булган елгалар санала. Уртача биләмәләргә азык, саклау һәм оя ясау өчен уңайлы булмаган биләмәләр керә.

Начар биләмәләргә көчле агымлы, туфрагы һәм ярлары ташлы булган һәм агачлар һәм куаклар үсми торган елгалар, шулай ук акрын агымлы, ләкин ярлары яшәү өчен яраклы булмаган җирләр белән аралашып торучы (комлы, ташлы, су баса торган, кыш көне ката торган), азык табу, саклау һәм оя ясау өчен уңайлы булмаган елгалар керә.

Бурсык.

Бурсыклар бөтен төр урманнарда яши, ләкин яфраклы һәм катнаш урманнарга яисә куе үсемлекле ландшафтларга күбрәк өстенлек бирә. Шәһәрләрдәге бакчалар һәм зур парклар, әгәр дә анда оя ясарга мөмкинлек булса, шулай ук бурсыкның яшәү тирәлегенә керә. Шулай ук алар урман кырыйларында һәм аларга якын яткан болыннарда һәм көтүлекләрдә урнаша; юеш урыннардан качалар. Татарстан Республикасында бурсык өчен яхшы биләмәләр категориясенә вак яфраклы токымнар өстенлек иткән урманнар (вак яфраклы токымнар 60-80%) һәм киң яфраклы токымнар булган катнаш урманнар керә. Уртача биләмәләргә кисентеләр һәм үсемлекләр белән капланган кырлар, ә шулай ук яфраклы куаклыклар булган яшь агачлыклар керә. Татарстан Республикасы территориясендә бурсык яшәү өчен начар биләмәләр категориясенә мәңге яшел ылыслы урманнар, ылыслы агачлар өстенлек иткән катнаш урманнар, Үзгәртелгән һәм зарар күргән участоклар (янган урман урыннары, җил сындырган агачлыклар) керә.

Дала байбагы.

Байбак – кыяклы ашлыклы-төрле үләнле тигез далалар җәнлеге. Даланы сөргән очракта, байбаклар тизрәк якындагы сөрелмәгән җиргә күченә яисә бер дә булмаса, «яшәү өчен уңайсыз» урыннарга да китәргә мөмкин: кысыр җирләр, чокырларның сөрелмәгән ярлары, елга үзәннәре, ызаннар, көтүлекләр һәм хәтта авыллар арасындагы юлларга. Авыл хуҗалыгының үсеше һәм шуның нәтиҗәсендә, Татарстан Республикасы территориясендә агроценозларның киң таралуы белән бәйле рәвештә, байбак яшәве өчен яраклы участоклар хәзерге вакытта сөрүлек җирләренең бик аз өлешен алып тора. Ул ашлыклар һәм яшелчәләр үсә торган урыннарда яшәми, андый урыннарда байбак мәҗбүри рәвештә яисә вакытлыча гына урнаша. Озаграк вакытка күпьеллык үләннәр чәчүлекләрендә тоткарлана. Терлекләр көтүлекләре һәм кешеләрнең янәшә булуы аңа йогынты ясамый.

Кондыз.

Кондыз яшәү өчен иң әйбәт булып, кечкенә һәм уртача зурлыктагы елгалар, иске елга үзәннәре, үзәнгә кермәгән күлләр, сугару канаулары, гөрләвекләр, торф карьерлары очрый торган җирләр тора. Шул ук вакытта әлеге җирләрдә азыкның булуы да әһәмияткә ия. Иң яхшы азык булып тал куаклыклары, усак өстенлек иткән яфраклы утыртмалар, каен, имән, карама, өрәңге, корыч-агач, юкә, чикләвек, шомырт агачлары катнашкан катнаш утыртмалар тора.

Уртача биләмәләргә елга тугайларында зур агачлар һәм зирек өстенлек итә торган торган, су басмый торган калкулыклар булмаган, зур елгаларның иске үзәннәре һәм үзәннәре, анда башка куаклыклар һәм агачлар үсми торган яр сызыгы участоклары керә.

Начар биләмәләр дип, ашарга ярамый торган куаклыклар һәм агачлар үсә торган утыртмаларны исәпләргә була.

Бәянең түбәнәюенә, бу төргә кешенең тискәре йогынтысы – хайваннар көтү, печән чабу, балык тоту, җыела торган суларны агызу, территорияләрне киптерү һәм кешенең турыдан-туры әлеге төрне җәберләве нигез булып тора.

Су күсесе.

Су күсесе яши торган биләмәләргә елга-сазлык үсемлекләре үскән, оя ясарлык ярлары булган барлык сулыкларны кертеп карарга мөмкин.

Елга-сазлык биләмәләренең җитештерүчәнлеген билгеләгәндә, үсемлекләрнең төрен, аның структурасын һәм мәйданын күрсәтү бик мөһим. Ул сулыкның файдалы мәйданын билгеләргә һәм су күсесенең саклану, оя кору, азык табу өчен шартлар белән тәэмин ителүе турында фикер йөртергә ярдәм итә.

Бәя биргәндә су күсесе ашый торган үсемлекләрнең ничек үсүенә һәм аның әлеге үсемлекләрне таба алуын ачыклауга аерым игътибар юнәлтелде.

Су күсесе өчен түбәндәге үсемлекләр төп азык булып тора: күл камышы, тар яфраклы һәм киң яфраклы камыш, кылыч үлән, кыяклар, су кәбестәсе, наратбаш (сазлык, елга буе), кырлы куга, ак төнбоек, сары чәчәк, төнбоек, ежеголовник, өч яфраклы вахта, акканат, канада элодеясы, бака тәңкәсе, җир-су карабодае, валлиснерия, агулы вех, тал ботаклары һәм кайрысы. Үсемлек ризыгы аз булган яисә бөтенләй булмаган очракта ул хайваннардан алынган азыкка да күчәргә мөмкин (моллюсклар, җансыз балыклар, бакалар, катыканатлар).

Кышкы чорда сулыкларның катуы да мөһим роль уйный: кыш көне азык табу суның нинди тирәнлектә һәм күпме вакытка катуына бәйле. Күп кенә күлләрдә һәм елгаларда кыш көне су күсесенә тискәре йогынты ясый торган боз катламы барлыкка килә. Су өсте катмый калса, киресенчә уңай йогынты ясый.

Сулыкларга сыйфатлы бәя бирү өчен аларның файдалы мәйданын дөрес күзалларга кирәк. Сулыкларның файдалы мәйданы дигәндә, су күселәренә оя кору өчен уңайлы, шулай ук азык табу һәм саклану өчен яхшы шартлары булган участоклар бергәлеге аңлашыла. Сулыкларның оя ясарга яраклы урыннары дип түбәндәгеләр санала:

оя ясау өчен яраклы, биек су басмый торган ярлар;

су күсесе үзенә оя ясый ала торган камышлыклар, тоташ утраулар, куе камыш куаклары;

яр буе су үсемлекләре капламы яки су үсемлекләре капламыннан барлыкка килгән зур утраулар, су күсесе оя ясый һәм азык таба алырлык 10 м киңлектәге массивлар.

Азык таба алырлык участоклар булып, 100 метр киңлектәге су үсемлекләре капламы санала. Һәр төр сулык чикләрендә, аларның сыйфатларына карап, биш бонитет бүлеп карала.

I бонитет – су күсесе яшәү өчен уңайлы сулыклар. Аларның бөтен мәйданы – файдалы мәйдан булып тора. Сулыклар, уртача 1 га мәйданда бер су күсесе семьясы яшәүне күздә тоткан уңайлы шартларга ия.

II бонитет – яхшы сулыклар. Шактый күп файдалы мәйданы бар, сулыкның калган өлеше мелиорация юлы белән чагыштырмача җиңел итеп шулай ук файдалы мәйданга әйләндерелә ала. Кышкы чорда яхшы азык базасы җәнлекләр санының күп булуын тәэмин итә – 1 га мәйданда 0,4 – 0,9 семья. Бу эчке яисә утраулы су үсемлекләре капламы булган сулыклар.

III бонитет – канәгатьләндерерлек сулыклар. Аларның шактый зур мәйданы, күп көч таләп итмәүче мелиорация чараларын уздырганнан соң, су күсесен күчерергә яраклы була. Файдалы мәйданы зур түгел. Кышкы чорда потенциаль файдалы мәйдандагы азык базасы җәнлекләрнең 1 га мәйданда 0,1 – 0,3 семья яшәвен тәэмин итә ала. Бу – су кырыенда камыш куаклары үскән сулыклар.

IV бонитет – уртача сулыклар. Файдалы мәйданы чикләнгән. Потенциаль файдалы мәйданы шактый зур, ләкин аны шактый күп көч таләп итүче мелиорация эшләреннән соң гына кулланып була. Кышкы чорда азык базасы нык кими, су күсесенең яшәү мәйданы 1 га сулыкка – 0,05 – 0,09 семья туры килә. Бу яр буе су үсемлекләре капламы булган сулыклар.

V бонитет – файдалы мәйданы чикле булган начар сулыклар. Потенциаль файдалы мәйданы зур түгел яки бөтенләй юк. Кыш көне азык бик аз, сулыкның күп җире кату сәбәпле азык табу кыенлаша. Су күсесе яшәү мәйданы 1 га сулыкка 0,05 семьядан артмый. Бу – су кырыенда камышлыклар булган күлләр.

Су күсесе яши торган сулыкларның тасвирламасын яки инвентаризациясен ясаганда, һәрбер сулыкка аерым исәп карточкасы ясала.

Тиен.

Тиеннең бөтен яшәеше урман белән бәйле. Тиеннәр яшәү өчен иң яхшы урын булып куе ылыслы урманнар яисә куе ылыслы агачлар күбрәк очраган урманнар тора. Беренче чиратта, бу чыршылар һәм эрбет наратының төрле төрләре.

Уңыш күп булган елларда кедр һәм чыршы урманнарында гаять күп орлыклар өлгерә. Агачларның куе ябалдашы тиеннәргә ерткычлардан сакланырлык ышык урын бирә. Мондый ябалдашларда хайваннарга үзләренә дә яшеренергә, ояларын да яшерергә җайлы. Моннан тыш, кышын бу агачларда бик күп кар җыела һәм алар астындагы җир кар белән капланмыйча кала. Шулай итеп, тиеннәргә җир эчендә саклый торган запасларын озаклап казып алырга туры килми.

Ак чыршы урманнарын тиеннәр азрак ярата. Алар да саклану өчен яхшы урын булып тора, ләкин куе ылыслы урманнар белән чагыштырганда, аларда азык азрак. Моннан тыш алар күп карлы сөзәклекләрдә үсә.

Наратлыклар, куе ылыслы яки ак чыршы урманнарына караганда, тиеннәргә саклану өчен начаррак урыннар булып тора. Һәм наратлыкларда, куе ылыслы урманнардан аермалы буларак, азык азрак. Ләкин аларда азыкны күбрәк табарга була. Чыршы уңышы азрак булган елларда, тиеннәрнең шактый зур өлеше нарат урманнарына күчә. Алар биредә уңдырышсыз чорны кичерә. Наратлыклар – бердәнбер ылыслы агачлар булган районнарда тиеннәрнең яшәеше алар белән бәйле.

Яфраклы урманнарда тиеннәргә саклану өчен урын азрак. Бу районнарда үрчү чорында җәнлекләр елга һәм инеш үзәннәренә, чыршы үсә торган урыннарга күченә.

Вак яфраклы урманнарга тиеннәр азык аз булган елларны җәй көне генә килә. Бары тик су баса торган тирәк-тал урманнары һәм каенлыклар гына искәрмә булып тора. Анда тиеннәр даими яши, ләкин аларның саны аз һәм гел кими.

Киң яфраклы урманнар үзләренең саклану урыннары ягыннан тиеннәр өчен күбрәк туры килә. Ләкин шуңа да карамастан, тиеннәр анда бары тик уңдырышлы елларда гына яши. Тиеннәр даими яшәүче шул ук эрбер-киң яфраклы агачлар, чыршы-ак чыршы һәм бук агачы-ак чыршы урманнарыннан аермалы буларак.

Аеруча шуны билгеләп үтәргә кирәк, куе ылыслы агачлардан торган тоташ урманнар тиеннәр яшәү өчен уңайлы түгел. Уңдырышсыз елларда тиеннәргә азык эзләп күчеп йөрергә туры килә.

Тиеннәргә яшәү өчен уңайлы урыннар булып бер территориядә төрле составтагы ылыслы агачларның мозаика рәвешендәге кушылмасы тора. Яисә урманда киң яфраклы агачлар булуы. Бу очракта тиеннәр, азык эзләп, якындагы күрше участокларга, бер урыннан икенче урынга күчә. Һәм аларга зур аралыклар үтәргә туры килми. Җәнлекләр урманның бер төрендә яхшы азык базасы һәм икенчесендә саклану өчен яхшы урыннар таба. Нәкъ менә шундый районнарда тиеннәр саны күп һәм елдан-ел тотрыклы була. Хәтта уңдырышсыз ел булган очракта да.

Тиеннәр даими җимеш бирә торган җитлеккән урманнарны артыграк күрә. Яшь үсентеле зоналарга алар бары тик сирәк кенә җәй көне күчә. Җитлеккән урманнарда тиеннәр үзләре өчен саклану урыннарын күбрәк таба. Аларда куышлы агачлар ешрак очрый. Ә куе ботаклар арасында тиеннәргә ояларын яшерергә җиңелрәк.

Сусар.

Сусар – урманда яшәүгә яраклашкан һәм ачыклык урыннарда яшәмәүче аучылык ресурсларының бер төре. Сусар өчен аучылык хуҗалыгы бонитетының төрен билгеләгәндә Г.Н. Бурдуков, В.М. Козлов тарафыннан эшләнгән методик кулланма нигез булып торды.

Сусар өчен яхшы биләмәләргә (I–II) беренче яруста чыршы һәм (яисә) ак чыршы үскән ылыслы урманнар керә.

Уртача биләмәләргә (III) уртача яшьтәге наратлыклар һәм сазлыкта үсүче чыршы урманнары керә.

Начар биләмәләр (IV–V) – бөтен яшьтәге яфраклы урманнар, карт нарат урманнары, 20 яшькә кадәрге яшь наратлыклар.

Суер (урман тавыгы).

Суерлар өчен типик яшәү урыннары – нарат агачлары өстенлек иткән карт ылыслы урманнар. Суер өчен яхшы биләмәләр булып 0,4–0,5 озынлыкта, аланлы, җиләклекләр (нарат җиләге, караҗиләк яки мүк җиләге), наратның, чыршының, артышның яшь һәм вак агачлары үсеп килә торган, кыяклар һәм төрле үләннәр булган, карт наратлыклар яки наратлар өстенлек иткән карт урманнар тора. Татарстан Республикасында андый җирләр юк диярлек.

Сыйфатлары буенча уртача биләмәләргә карт сирәк һәм уртача куелыктагы яфраклы һәм яфраклы-ылыслы агачлар, төрләре буенча яшел, ак мүк һәм үлән белән капланган, ә шулай ук сфагнум мүкле наратлыклар һәм мүк җиләге белән капланган

сазлыклар керә. Республика мәйданыннан андый җирләр 2 % тәшкил итә.

Начар биләмәләр категориясенә яшь һәм урта яшьтәге урманнар, шулай ук яшь һәм вак агачлары, үләм капламы булмаган җитлеккән агачлар керә.

Биләмәләрнең сыйфатына һәм суерның санына йогынты ясый торган факторлардан, кеше эшчәнлеге хәлиткеч булып тора: урманнарны күпләп кисү, киртләү, терлек көтү, печән чабу, җиләкләр һәм гөмбәләрне күпләп җыю суерның яшәү шартларына шул кадәр начар йогынты ясый һәм шуңа күрә аның саны кими. Татарстан Республикасы территориясендә суер яшәү өчен яраклы биләмәләр IV бонитетка кертелә. Ләкин суерның яшәү урыннарына зур антропоген йөкләнеш белән бәйле рәвештә бонитет классы V төште.

Көртлек.

Көртлек яшәү өчен биләмәләргә бәя биргәндә барлык төр урманнар һәм аларга тоташып торучы 0,5 км киңлектәге биләмәләр игътибарга алына. Көртлек яшәү өчен яхшы биләмәләр булып:

бай җиләклекләрдән торган (каен җиләге, нарат җиләге, каражиләк, кызыл бөрлегән) һәм төрле үләннәр үскән аланнары һәм аланлыклары булган катнаш төрдәге яшь агачлыклар, куаклыклар (тал, зелпе, артыш, кура җиләге, карлыган);

вак агачлар үсеп килә торган һәм җиләклекләр, төрле үләннәр капламы булган карт сирәк урманнар, күбесенчә каенлыклар тора.

Уртача категорияле биләмәләргә түбәндәгеләр керә:

аланнары булган, төрле үләннәр, җиләклекләр үскән барлык уртача куелыктагы карт урманнар (сазда үскән зиреклекләрдән башка) һәм җиләклекләр булган төрле составтагы яшь урманнар;

куаклыклар белән капланган болыннар һәм печәнлекләр.

Начар биләмәләргә алансыз куе карт урманнар, уртача яшьтәге яфраклы һәм ылыслы яшь агачлар, шулай ук бернинди агачлар һәм куаклыклар үсми торган кыяклы һәм сфагнум мүкле сазлыклар керә. Көртлекнең яшәеш шартларына кешенең хуҗалык эшчәнлеге хәлиткеч йогынты ясый, иң беренче чиратта, терлек көтү һәм иртә печән чабу. Биләмәләргә кеше күп килү белән бәйле гөмбә һәм җиләк җыю һәм урманнан башкача файдалану, шулай ук көртлекнең санына начар тәэсир итә. Хуҗалык эшчәнлеге күп алып барыла торган биләмәләрне, аларның төренә дә карамастан, начар биләмәләр категориясенә кертеп карарга кирәк.

Боҗыр.

Боҗыр – күбесенчә тайга тибындагы урман кошы. Боҗырның төп яшәү урыны булып тигез урында урнашкан чыршылык яки ылыслы-яфраклы тайга. Боҗыр вак яфраклы агачлар – каен, зирек, тал, усак белән катнаш куе ылыслы урманнарда, шулай ук ылыслы-яфраклы катнаш урман белән капланган чокырлы урыннарда оя кора. Дымлылык, чүп, вак агачлар һәм үлән капламы, ә шулай ук җиләклекләр аның санына уңай тәэсир итә. Аны беркайчан да кырда, сазлыкта, таулы тундрада очратып булмый. Бер генә төр агачлар, мәсәлән, нарат һәм яфраклы урманнар үсә торган сирәк урман массивларында, шулай ук урман паркларында яшәми. Боҗыр шулай ук урман кырыйларына да, урман кырыеннан 200-300 метрдан якынрак арага килми.

Киек су кошлары.

Киек су кошлары өчен теге яки бу төр үсемлекле сулыкларның (елгалар, күлләр, сазлыклар, иске торф чыгару карьерлары, сусаклагычлар, мелиорация каналлары) аерым участоклары гына түгел, ә аларның функциональ билгеләнеше – оя кору, бала чыгару, оя кормыйча яшәү стацияләренә караучы төркемнәре бәяләнә.

Аучылык хуҗалыгы күзлегеннән киек су кошлары яшәү урыннарын бәяләүнең иң мөһим критерийларының берсе – биләмәләрдә азык табу мөмкинлеге.

Елга үрдәкләре өчен оя кору стацияләре булып сал агызу урыннары һәм турыдан-туры сулыклар янында, алардан 100 метр ераклыкта урнашкан урман, куаклык һәм үлән капламы участоклары. Чума торган үрдәкләр өчен тагын бирегә су өстендә куе булып үсүче камыш, җикән камыш участокларын да кертергә кирәк.

Бала чыгару яки азык табу төрендәге стацияләргә кыяк үләне, ежеголовник, сай сулык буенча наратбаш һәм водокрасның су өстендәге өлеше, шулай ук елганың тирән булмаган, яфраклары суда йөзеп йөрүче яисә суга кереп торучы су үсемлекләренә бай ике утрау арасындагы киң җире керә.

Оя кормыйча яшәү стацияләренә шактый зур чиста тирән сулы елганың ике утрау арасындагы киң җире керә.

Бонитет классына күчкән вакытта бәя бирелүче территориядә киек су кошлары өчен кирәкле бөтен төр стацияләрнең дә булуын ачыклыйлар. Гамәлдә стацияләрнең иң яхшы нисбәте булып 10 % оя ясау, 50 % азык табу, 40 % оя кормыйча яшәү стацияләре булу санала.

Гомумән алганда, төбәк буенча биләмәләрнең саклану-оя ясау төре начар дип; сазлыклар мәйданы һәм сулыкларның үләннәр белән капланып килүче өлеше (сулыкларның гомуми мәйданыннан уртача 20 %) кергән бала чыгару-азык табу төре яхшы дип; оя кормыйча яшәү төре (сулыкларның үлән белән капланмаган өлеше) уртача дип бәяләнә.

2.2. Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурслары яшәү тирәлеге элементларын сыйфат ягыннан комплекслы бәяләү нәтиҗәләре.

Поши өчен яшәү тирәлегенә комплекслы бәяләү, башка төрләр шикелле үк, 12 нче таблицада бирелгән. Аучылык биләмәләренә йомгак бәяләмә – 13 нче таблицада. Татарстан Республикасының поши яшәргә яраклы аучылык биләмәләре IV класс бонитетка кертелә.

Татарстан Республикасының себер кыр кәҗәсе өчен аучылык биләмәләре III бонитетка карый, IV класска кадәр төшә ала (13 нче таблица). 12 нче таблицадан күренгәнчә, яхшы биләмәләргә кисентеләр һәм үләннәр белән капланып килүче басулар, яфраклы яшь агачлар, үлән капламы өстенлек иткән тугайлыклар керә. Кыр кәҗәсе өчен уртача стацияләр булып, вак яфраклы токымнар өстенлек иткән урманнар һәм киң яфраклы токымнар (60 % ким булмаган) булган катнаш урманнар тора. Яшәү өчен начар урыннарга мәңге яшел ылыслы урманнар, ылыслы агачлар өстенлек иткән катнаш урманнар һәм сазлыклар керә. Кыр кәҗәсе өчен бонитет республикада кар капламы биек булу белән бәйле рәвештә, 1 класска төшерелде. Моннан тыш, республикада климат алмашыну аркасында, кыш көне температура үзгәрү һәм җепшек көннәр еш күзәтелә, ә бу үз чиратында каты кар өслеге

барлыкка китерә. Мондый шартларда кыр кәҗәләре өчен җир өстендә азык табу проблемасыннан тыш, боз катламы нәтиҗәсендә яралану куркынычы да барлыкка килә.

Татарстан Республикасында Кабан дуңгызы өчен аучылык биләмәләрен исәпләү бонитеты – II, ләкин төбәккә хас биек кар капламы (35–40 см), шулай ук республикабызда күзәтелә торган каты кар өслеге, бозлавык һәм җир кату белән бәйле рәвештә Кабан дуңгызы өчен бонитет 1 класска төшерелде. Шулай итеп, Кабан дуңгызы өчен Татарстан Республикасының аучылык биләмәләренә йомгак бәя – III.

Төбәктә ак куян өчен яхшы биләмәләргә кисентеләр һәм үлән белән капланып килүче болыннар, шулай ук яфраклы куаклар кертелде. Начарларга – сазлыклар, Үзгәртелгән һәм зарар күргән участоклар керә. Күпчелек биләмәләр уртача биләмәләргә керә. Татарстан Республикасында ак куян өчен исәпләү бонитеты – III. Ләкин әлеге төр яшәү тирәлегенә югары антропоген йогынты (республика урманнарында күпләп урман кичүләр, киртләүләр, гөмбә-җиләк җыю) һәм уртак яшәү тирәлеге территорияләрендә соры куян белән конкурентлык белән бәйле рәвештә, бу төр өчен бонитет 1 класска киметелде. Шулай итеп, Татарстан Республикасында ак куян өчен аучылык биләмәләренә йомгак бәя – IV (13 нче таблица).

Татарстан Республикасында соры куян яшәү өчен яраклы мәйдан 4 142 331,3 га тәшкил итә һәм V класс бонитетка карый. Яшәү тирәлегенә бертөрле таләпләр куелганга күрә, соры куян яшәү өчен яраклы биләмәләр мәйданы һәм аларның бонитеты соры кыр тавыгы белән туры килә. Татарстан Республикасының территориясендә бу төр яшәү өчен яраклы биләмәләр мәйданы 4 142 331,3 га тәшкил итә. Бу җирләр V класс бонитетка кертелде.

Америка чәшкесе. Республика территориясендә чәшке өчен яхшы биләмәләр булып бай ихтиофауналы, җир-су хайваннары, амфибияләр һәм кысласыманнар күп яшәүче, агач-куаклыклар үскән текә ярлы, чүпләнгән, киң үзәнле, ермаклары, күлләре һәм иске үзәннәре булган елгалар тора. Татарстан Республикасында әлеге биләмәләрнең мәйданы 19 035,6 га тәшкил итә. Уртача биләмәләргә азык табу, саклану һәм оя ясау өчен шартлар начаррак булган елгалар кертелә. Республикада аларның мәйданы 6 857 га якын. Начар биләмәләр булып тиз агымлы, ташлы туфраклы һәм агачлары һәм куаклары булмаган елгалар керә, шулай ук ярлары яшәргә яраксыз җирләр (комлы, ташлы, су баса һәм кышын боз ката торган) белән чиратлаша торган акрын агымлы, азык табу, саклау һәм оя ясау өчен шартлар начар булган елгалар керә. Андый биләмәләрнең мәйданы – 18 129,4 га. Гомумән, Татарстан Республикасында чәшке яшәү өчен шартлар шактый әйбәт, шуңа күрә әлеге биләмәләр бонитетның II классына кертелде.

Татарстан Республикасы территориясендә бурсык яшәргә яраклы мәйдан 1 856 983,772 га тәшкил итә, республиканың гомуми мәйданыннан 27,4 %. Безнең регионда бурсык очень яхшы биләмәләр категориясенә вак яфраклы токымнар өстенлек иткән урманнар (вак яфраклы токымнар 60–80%) һәм киң яфраклы токымнар булган катнаш урманнар керә. Уртача биләмәләргә кисентеләр һәм үлән

белән капланып килә торган кырлар, шулай ук яфраклы куаклыклар булган яшь агачлыклар кирә. Татарстан Республикасы территориясендә бурсык өчен начар биләмәләр категориясенә мәңге яшел ылыслы урманнар, ылыслы агачлар өстенлек иткән катнаш урманнар һәм зыян китерелгән участоклар (янган урман урыннары, җил сындырган агачлыклар) керә. Гомумән алганда, бурсык яши торган биләмәләр II бонитетка карый. Бурсыкның яшәү шартларын анализлаганнан соң, бонитетның классы киметелде. Бурсык өчен йомгак бонитет – III. Бонитетның бер класска киметелүе әлеге төр яши торган җирләргә антропоген йөкләнеш белән бәйле.

Дала байбагы. Авыл хуҗалыгы үсеше һәм шуның нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы территориясендә агроценозларның киң таралуы белән бәйле рәвештә, байбак яшәве өчен яраклы участоклар хәзерге вакытта сөрүлекләрнең аз өлешен алып тора. Ул ашлыклар һәм яшелчәләр утырткан урыннарда яшәми; андый урыннарда байбак ихтыярсыз рәвештә яисә вакытлыча гына урнаша. Күпьеллык үләннәр чәчүлекләрендә озаграк вакыт яши. Хайваннар көтүлекләре һәм кеше янәшәлеге аңа йогынты ясамый. Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, республикада байбак яши торган биләмәләр бонитетның V классына карый.

Кондыз. Татарстан Республикасында кондыз яшәү өчен яраклы биләмәләрнең мәйданы 56 444,63 га тәшкил итә. Кондыз яшәү өчен иң әйбәт җирләр булып, кечкенә һәм уртача елгалар, иске елга үзәннәре, тугайсыз күлләр, сугару каналлары, гөрләвекләр, торф карьерлары очрый торган җирләр тора. Шул ук вакытта әлеге җирләрдә азык таба алу зур әһәмияткә ия. Азык табу ягыннан иң яхшы җирләр булып куе тал куаклыклары һәм усак өстенлек иткән яфраклы агачлар, каен, имән, карама, өрәңге, корыч-агач, юкә, чикләвек, шомырт агачлары булган катнаш урманнар санала. Азык табу өчен начаррак җирләргә елга тугайларында зур агачлар һәм зирек өстенлек иткән, су басмый торган калкулыклар булмаган, зур елгаларның иске үзәннәре һәм үзәннәре, аннан башка куаклыклар һәм агачлар үсми торган яр буе сызыгы участоклары керә. Начар җирләр дип, ашарга яраклы булмаган куаклыклар һәм агачлар үсә торган утыртмаларны исәпләргә була. Татарстан Республикасы өчен уртача бонитет – IV.

Суер яши торган җирләрнең сыйфатына һәм аларның санына йогынты ясый торган факторлардан кеше эшчәнлеге хәлиткеч булып тора: урманнарны кисү, киртләү, терлек көтү, печән чабу, күп итеп җиләкләр һәм гөмбәләр җыю суерның яшәү шартларын шул кадәр начар тәэсир итә ки, аның саны бик күпкә кими. Татарстан Республикасы территориясендә суер өчен яраклы җирләр IV бонитетка кертелә. Ләкин суерның яшәү урыннарына зур антропоген йөкләнеш белән бәйле рәвештә бонитетның классы V төште. Көртлек яшәү өчен җирләргә бәя биргәндә барлык төр урманнар һәм аларга тоташкан 0,5 км киңлектәге ачыклык җирләр игътибарга алына.

Көртлек яшәү өчен яхшы җирләр булып, җиләклекләр һәм төрле үләннәр белән капланган аланнары һәм аланлыклары булган яшь катнаш урманнар, вак агачлар (тал, зелпе, артыш, кура җиләге, карлыган), күбесенчә каеннардан торган, вак куаклыклары булган, җиләклекләр һәм төрле үләннәр үскән сирәк карт урманнар тора. Уртача категорияле җирләр булып вак яфраклы агачлар өстенлек иткән (вак

яфраклы агачлар 60–80%) катнаш урманнар керә. Начар җирләр булып киң яфраклы карт урманнар (киң яфраклы токымнар 30 % артык) һәм сазлыклар тора (12 нче таблица).

Боҗыр. Аның белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә бу төр яшәү өчен уртача җирләр булып, вак яфраклы агачлар өстенлек иткән урманнар һәм киң яфраклы агачлар булган катнаш урманнар тора. Ә кисентеләр һәм үлән белән капланып килә торган болыннар, яфраклы куаклыклардан торган яшь агачлыклар, сазлыклар бу төр яшәү өчен начар җирләр булып тора.

Киек су кошлары. Аучылык хуҗалыгы күзлегеннән караганда, киек су кошлары яши торган биләмәләрне бәяләгәндә, иң беренче критерийлардан азык табу шарты куела.

Биләмәләр сыйфатының уртача бәяләмәсе бөтен Татарстан Республикасы территориясе өчен ясалды. Уртача күрсәткеч зурлыгы бонитетның теге яисә бу классына кертеп карала алмый, чөнки ул биләмәләрнең барлык сыйфатларын да үз эченә алмый, ә азык табу ягыннан гына бәя бирә. Татарстан Республикасының киек су кошлары яшәргә яраклы биләмәләр IV класс бонитетка кертелде.

12 нче таблица

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларының төп төрләре яшәү тирәлегенә комплекслы бәяләмә

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Поши | Кабан дуңгызы | Кыр кәҗәсе | Ак куян | Соры куян, соры көртлек | Янутсыман эт | Тиен | Сусар | Бурсык |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Урманнар | Мәңге яшел ылыслы (мәңге яшел ылыслы токымнар 80 % артык) | 30% – яхшы, 70% – начар | уртача | начар | 25% – яхшы, 75% – начар | - | начар | 10% – яхшы, 40% – уртача, 50% – начар | 35% – яхшы, 15% – уртача, 50% – начар | начар |
| | | Вак яфраклы (вак яфраклы токымнар 80 % артык ) | 40 % – уртача, 60 % – начар | уртача | 15 % – яхшы, 85 % – уртача | 10 % – яхшы, 50 % – уртача, 40 % – начар | - | начар | 50 % – уртача, 50 % – начар | начар | яхшы |
| | | Киң яфраклы (киң яфраклы токымнар 30 % артык) | 20 % – уртача, 80 % – начар | яхшы | 20 % – яхшы, 80 % – начар | 50 % –уртача, 50 % –начар | - | 10% – уртача | 25 % – уртача, 75 % – начар | начар | уртача |
| | | Ылыслы токымнар өстенлек иткән катнаш (ылыслы токымнар 60–80 %) | уртача | уртача | начар | 25 % – яхшы, 75 % – начар | - | начар | 10 % – яхшы, 40 % – уртача, 50 % – начар | 35 % – яхшы, 15 % – уртача, 50 % – начар | начар |

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Поши | Кабан дуңгызы | Кыр кәҗәсе | Ак куян | Соры куян, соры көртлек | Янутсыман эт | Тиен | Сусар | Бурсык |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |
| | | Вак яфраклы токымнар өстенлек иткән катнаш (вак яфраклы токымнар 60–80 %) | уртача | уртача | уртача | уртача | - | начар | 50 % – уртача, 50 % – начар | начар | яхшы |
| | | Киң яфраклы токымнар булган катнаш (киң яфраклы токымнар 30 % ким) | начар | яхшы | уртача | 50 % – уртача, 50 % – начар | - | 10% – уртача | 25 % – уртача, 75 % – начар | начар | яхшы |
| 2 | Яшь агачлар һәм куаклар | Кисентеләр һәм үлән белән капланган кырлар | яхшы | уртача | яхшы | яхшы | яхшы | уртача | - | - | уртача |
| | | Яфраклы куаклар | яхшы | уртача | яхшы | яхшы | яхшы | уртача | - | - | уртача |
| 3 | Сазлыклар | Үләнле | начар | начар | начар | начар | 10 % – яхшы | яхшы | - | - | начар |
| 4 | Болын-дала | Болыннар | - | 20 % – уртача | 10 % – начар | - | яхшы | 20 % – уртача | - | - | 10 % – яхшы |
| 5 | Авыл хуҗалыгы биләмәләре | Сөрүлек җирләр | - | - | 10 % – начар | - | начар | 20 % – уртача | - | - | 10 % – яхшы |

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Поши | Кабан дуңгызы | Кыр кәҗәсе | Ак куян | Соры куян, соры кәртлек | Янутсыман эт | Тиен | Сусар | Бурсык |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге болыннар (печәнлекләр һәм көтүлекләр) | - | 20 % – уртача | 10 % – начар | - | уртача | 20 % – уртача | - | - | 10 % – яхшы |
| 6 | Эчке су объектлары | Су агымнары | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | | Сусаклагычлар | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | | Күлләр, бөяләр | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 7 | Тугайлык комплекслары | Үләннәр өстенлек иткән (урман һәм куаклар 20 % кадәр) | 20 % – яхшы | уртача | яхшы | 20 % – яхшы | 20 % – яхшы | яхшы | - | - | - |
| 8 | Яр комплекслары | Эчке су объектларының яр комплексы | начар | - | уртача | начар | яхшы | уртача | - | - | начар |
| 9 | Үзгәртелгән һәм зарар күргән участоклар | Үзгәртелгән һәм зарар күргән участоклар (янган урманнар, торф чыгару урыннары, җилдән ышыклау валлары һ.б.) | начар | - | начар | начар | начар | - | - | - | начар |

12 нче таблицаның дәвамы

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Байбак | Суер | Көртлек | Божыр | Су күсесе | Кондыз | Чәшке |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Урманнар | Мәңге яшел ылыслы (мәңге яшел ылыслы токымнар 80 % артык) | - | яхшы | начар | 30 % – яхшы 70 % – начар | - | - | - |
| | | Вак яфраклы (вак яфраклы токымнар 80 % артык ) | - | начар | 30 % – яхшы, 70 % – начар | начар | - | - | - |
| | | Киң яфраклы (киң яфраклы токымнар 30 % артык) | - | начар | начар | начар | - | - | - |
| | | Ылыслы токымнар өстенлек иткән катнаш (ылыслы токымнар 60–80 %) | - | уртача | начар | 30 % – яхшы, 70 % – начар | - | - | - |
| | | Вак яфраклы токымнар өстенлек иткән катнаш (вак яфраклы токымнар 60–80 %) | - | начар | уртача | уртача | - | - | - |
| | | Киң яфраклы токымнар булган | - | начар | начар | уртача | - | - | - |

| Т/с | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге категорияләре | Аучылык ресурслары яшәү тирәлеге класслары | Байбак | Суер | Көртлек | Божыр | Су күсесе | Кондыз | Чәшке |
